• ВАКЫЙГА •

«ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ» ГАЗЕТАСЫНА ЯЗЫЛ

*2019 елның 1 яртысына язылу бәясе 132 сум. Язылу индексы П4333*

• СОРАУ – ҖАВАП •

АЗАННАН СОҢ НИНДИ ДОГА КЫЛЫНА?

*7 бит*

• ИМАНЛЫ ГАИЛӘ •

ИСЛАМДА ТӘРБИЯГӘ БАЛА АЛУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

*10 бит*

• НӘСЫЙХӘТ •

КОРЪӘН-ХАФИЗДАН 20 КИҢӘШ

*14 бит*

*№ 1 (282)* *Татарстан мөселманнары диния нәзарәте басмасы* *рабигыль-ахыр – раҗәб 1440*

*Гыйнвар, 2019*

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# Диния нәзарәте Пленумының 2019 елда беренче утырышы



*Дәвамы 8 нче биттә*

12+

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

# Мәккәдә Россия хаҗ миссиясе вәкилләре очрашуы узды



Гыйнвар аенда Мәккәдә Россия хаҗ миссиясе вәкилләренең Согуд Гарәбстанының хаҗ министрлыгында очрашуы уздырылды. Очрашуны министр урынбасары Габделфәттах бине Сөләйман Машшат үткәрде. Россия хаҗ миссиясе делегациясен Чечня мөфтие Сәлах Мәҗиев җитәкләде. Татарстан Республикасыннан җыелышта «ДУМ РТ Хаҗ» генераль директоры Ранис хәзрәт Вахитов катнашты. Катнашучылар арасында Россиянең башка хаҗ операторлары вәкилләре дә бар иде.

Чарада 2019 ел сезонында хаҗны оештыру мәсьәләләре турында фикер алыштылар һәм 2018 ел хаҗ сезонына йомгак ясадылар.

Хаҗ министрлыгында очрашулар ел саен уздырыла. Алар ярдәмендә хаҗны оештыруга күпсанлы яңалыклар кертелә. Россия хаҗ миссиясенең Согуд Гарәбстаны хаҗ министрлыгы белән актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә хаҗиларга хезмәт күрсәтү сыйфаты артуын күзәтергә мөмкин. Әйтик, 2018 елда бөтен хаҗилар да Изге җир территориясе чикләре аша электрон визалар белән узды, Гарәфә үзәнлегендә сәнәгать кондиционерлары куелган яңа палаткалар урнаштырылды, гомумән алганда, хаҗның барлык этаплары оештыруның дәрәҗәсе артты.

Россия хаҗ миссиясенең Мәккәдәге эше тагын берничә көн дәвам итәчәк. Транспорт, хезмәт күрсәтү, яшәү, виза һәм башка юнәлешләр буенча җаваплы төрле ведомстволарның вәкилләре белән очрашулар планлаштырыла.

# Нәзарәт чыгарган Коръән басмалары Төркиядә югары бәяләнде



Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми делегациясе Төркиядә эшлекле очрашуларны дәвам итеп, Коръән басмаларын тикшерү буенча Төркия Комиссиясе башлыгы Госман Шаһинда булдылар. Әлеге чарада Татарстан мөфтияте тарафыннан бастырылган Коръәннәргә комиссиянең профессиональ уңай бәясе бирелде. Үз чиратында, Госман бәй Коръәннең 10 кыйраәте буенча Шиһабетдин Мәрҗанинең билгеле хезмәтенә карата үзенең тирән кызыксынуын белдерде – дин эшлеклесе әлеге тема буенча фәнни-тикшеренү эше алып бара. Шуңа күрә, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендәге делегация аңа истәлеккә Мәрҗанинең алты томлык хезмәтләрен бүләк итте.

Моннан тыш, Татарстан делегациясе Төркиянең дин эшләре министры Әли Эрбашта да булды. Очрашуда катнашучылар мөфтиятнең берничә проектын тормышка ашыру буенча фикер алыштылар, шул исәптән, Төрек министрлыгы белән бергәлектә башкарылачак эшләр хакында да сүз барды. Шул ук вакытта, Камил хәзрәт Сәмигуллин ел саен Рамазан аенда Татарстан Республикасына килә торган Коръән-хафизлар һәм Корбан бәйрәме көннәрендә халыкның мохтаҗ катламын ит белән тәэмин иткән өчен мөселманнар исеменнән Гали бәйгә рәхмәтен белдерде.

# Төркиянең IRCICA үзәгендә Мәрҗани мирасы турында фикер алыштылар



Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Истанбулда IRCICA Ислам тарихы, сәнгате һәм мәдәнияте тикшеренү үзәге генераль директоры Халит Ирэн белән очрашты. Очрашу барышында алар күренекле татар дин галиме Шиһабетдин Мәрҗанинең ислам дөньясында тоткан роле һәм урыны, шул исәптән, аның «Вафият әл-әсләф...» китабы турында фикер алыштылар. Хәзерге вакытта үзәктә галимнең әлеге хезмәте буенча фәнни-тикшеренү эше алып барыла. Халит бәй мөфтигә китапның икенче нөсхәсен эзләү нәтиҗәләрен бәян итте. Камил хәзрәт, үз чиратында, ТР мөселманнары Диния нәзарәте 2018 елда Мәрҗанинең тууына 200 ел тулу уңаеннан башкарган эшләр хакында сөйләде.

# Журналистлар өчен «Оедым мин ошбу имамга...» иҗади конкурсы игълан ителә

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте журналистлар өчен «Оедым мин ошбу имамга...» дип исемләнгән иҗади эшләр бәйгесе игълан итә. Конкурс җәмгыятьтә имамнарны борчыган мәсьәләләргә игътибарны җәлеп итү, дин әһелләренең абруен күтәрү максатыннан үткәрелә. Бәйге мәчет имамнарының эшчәнлеген уңай яктыртуга юнәлдерелгән.

Конкурс нәтиҗәсендә иң яхшы 5 иҗади эш билгеләнәчәк. Авторларның хезмәтләре киләсе номинацияләрдә бәяләнәчәк: «Иң яхшы телевизион материал», «Иң яхшы радиорепортаж», «Басма чарада иң яхшы язма», «Иң яхшы интернет-язма», «Иң яхшы фото/видеоретортаж». Шушы номинацияләрнең һәрберсендә бер җиңүче сайланачак. Җиңүчеләрне диплом һәм акчалата премияләр көтә. Конкурста рус яки татар телендә чыккан материаллар катнаша ала. Шунысы үзенчәлекле, бер автор конкурста берничә номинациядә катнашырга мөмкин.

Гаризалар 2019 елның 1 июленә кадәр Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 йорт, ТР МДН матбугат хезмәтендә кабул ителә. Бәйгегә нигезләмә dumrt.ru сайтында китерелә.

■ dumrt.ru

# Балалар өчен Коръән уку бәйгесе үтте




Казанның «Тынычлык» мәчетендә Коръән уку бәйгесе үтте. Әлеге ярыш мәхәллә мәчетенә йөрүче балалар арасында узды. Бәйгедә катнашкан яшүсмерләрнең Коръән-Кәримне уку, өйрәнү, ятлау күнекмәләренә Татарстан мөфтие дә үз бәясен бирде.

Бәйгедә Казанның Тынычлык бистәсендә яшәүче һәм Коръән укырга өйрәнүче егермегә якын бала катнашты. Алар барысы да мәртәбәле жюри алдында мөселманнарның Изге Китабын ни дәрәҗәдә белүләрен күрсәтте. Катнашучылар зур критерийлар белән бәяләнсә дә, алар сынатмадылар, сан ягыннан гына түгел, гыйлемлелек дәрәҗәсе буенча да матур нәтиҗә күрсәттеләр.

Төрле номинацияләрдә катнашып, җиңү яулаган дистәгә якын балага истәлекле бүләкләр тапшырылды. Ин шә Аллаһ, киләчәктә татар халкында яңа Коръән-хафизлар буыны тәрбияләнеп чыгуда Тынычлык мәхәлләсе күркәм өлеш кертүчеләрдән булыр!

■ dumrt.ru

# Баш казыйдан нәсыйхәт



Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәдә читтән торып уку бүлеге шәкертләре белән очрашуга күренекле остазыбыз, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев килде. Ул шәкертләр каршында вәгазь сөйләде һәм алар тарафыннан бирелгән күп кенә сорауларга җавап бирде.

Җәлил хәзрәт авылда имам-хатыйб, районда имам-мөхтәсиб, Татарстанның баш казые буларак, үз тәҗрибәсеннән чыгып кайбер нечкәлекләр хакында бәян кылды. Диннең торышына бәя биргәндә, ул нәкъ менә имамчылык вазифасын алган кешенең өстендә булган җаваплылыкка басым ясады. Шулай ук Җәлил хәзрәт динебездә мөһим булган кагыйдәләргә тукталды. Гыйбадәт, никах, әхлакый мәсьәләләргә басым ясап китте. Шәкертләрнең саны елдан-ел арта бара. Йөздән артык шәкертләр төрле төбәкләрдән (Самара, Ульян, Чувашия, Киров, Мәскәү, Свердловск, Башкортстан, Пермь, Мари-Эл һ. б.) гыйлем алу нияте белән килгәннәр.

Җәлил хәзрәтнең чыгышын зал тутырып очрашуга килгән шәкертләр игътибар белән тыңлады. Аның гади тормыштан алынган мисаллар белән баетылган зур чыгышы шундый тирән гыйлемле дин әһелләре белән аралашуга сусаган шәкертләр өчен бик файдалы булды. Мәдрәсә мөдире Ильяс хәзрәт Җиһаншин Җәлил хәзрәткә мәдрәсә мөгаллимнәре, шәкертләр исеменнән рәхмәт сүзләрен җиткерде.

# Мөслимәләр белемнәрен тикшерде



Яр Чаллы шәһәре «Ак мәчет» мәдрәсәсенең кичке һәм читтән торып уку бүлекләрендә белем алучы хатын-кызлар арасында Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам тормышына багышланган интеллектуаль уен – брейн-ринг уздырылды. Дүрт өлештән торган әлеге бәйгедә барлыгы дүрт команда катнашты. Катнашучылар ял итеп алган арада мәдрәсә мөгаллимнәре вәгазьләр сөйләде.

Бәйгенең гомуми нәтиҗәләре буенча «Ак мәчет» мәдрәсәсенең читтән торып укучы шәкертләреннән торган «Карлыгычлар» командасы I урынга лаек булды, кичке бүлектә белем алучыларның «Сандугачлар» командасы – II урында, шулай ук кичке бүлектә укучылардан оешкан «Сыерчыклар» командасына III урын бирелде.

■ dumrt.ru

## Мөхтәсибәтләрдә балалар өчен рухи-сәламәтләндерү чаралары төгәлләнде

Татарстан мөхтәсибәтләрендә кышкы каникуллар вакытында мәктәп укучылары өчен оештырылган рухи-сәламәтләндерү чаралары төгәлләнде. Аерым алганда, Бөгелмәнең Үзәк мәчетендә ислам нигезләренә 6-12 яшьләрдәге балалар төшенде. Алар сәламләү, ашауэчү әдәпләре белән танышты, әтиәниләргә карата нинди мөнәсәбәттә булырга кирәклегенә өйрәнде. Сабыйлар Коръән сүрәләре, догалар ятлады. Дәресләрне Бөгелмә мәчетләре хәзрәтләре һәм Урыссуның «Фәнис» мәдрәсәсе шәкертләре алып барды. Курслар тәмамлангач, балалар күмәкләшеп кинотеатрга юл тотты – биредә алар мультфильм карады.

Шундый ук курслар Түбән Кама мәчете каршындагы «Ихлас» рухиәхлакый тернәкләндерү үзәгендә оештырылды. Алты көн дәвамында малайлар тимераякта, чана-чаңгы шуды, саф һавада футбол һәм башка хәрәкәтчән уеннар уйнады. Шулай ук, әхлак, ата-анага карата хөрмәт, тәкъвалык кебек мөһим мәсьәләләрне колачлаган рухи әңгәмәләрдә катнашты. Ял программасында заманча күңел ачу чаралары да булды – әйтик, балалар күмәкләшеп мультфильм карарга кинотеатрга бардылар.

Кайбыч мөхтәсибәтендә кышкы каникуллар вакытында рухисәләмәтләндерү үзәкләре Олы Кайбыч, Кошман һәм Коланга авыллары мәчетләрендә эшләде. Әлеге курслар кысаларында балалар Коръән сүрәләре өйрәнде, төрле уеннарда һәм интеллектуаль ярышларда катнашты. Олы Кайбыч авылы мәчетендә, кышкы курсларның тәмамлануы уңаеннан, балаларга чәй өстәле әзерләнде, уеннар оештырылды һәм бүләкләр өләшенде. Кайбыч районы мөхтәсибәте әлеге чараны оештыруга ярдәм иткән Җиһангәрәев Искәндәр Рөстәм улына тирән ихтирамын һәм олы рәхмәтен белдерә.

Искәртеп узыйк: кышкы каникуллар чорында республикабызның 16 мәчетендә кызлар һәм малайлар өчен мәктәп укучылары өчен рухисәламәтләндерү чаралары оештырылды. Белем алу һәм күңел ачу программасына мастер-класслар, викториналар, шахмат буенча турнирлар, конкурслар, Коръән буенча дәресләр, Кәлам Шәриф уку һәм ятлау буенча ярышлар, тимераякта, чаңгыда шуу кертелде.

# «Киемгә хезмәт итмә, кием сиңа хезмәт итсен»



Гомумән, кием өч төрле вазифаны үти: төрле табигать күренешләреннән (эсселек, яңгыр, җил) саклый; кешене матурлап тора, бизи; башкаларга күрсәтергә тыелган урыннарны каплый.

Динебездә киемнең бу өч вазифасына да урын бар. Аллаһы Тәгалә «Әгъраф» сүрәсендә: **«Ий Адәм балалары! Без сезгә киемнәр яраттык, ул киемнәр гаурәтләрегезне каплар, янә мал яраттык һәм дә тәкъвалык киемен бирдек...»** – дип әйтә. Кием белән кеше гаурәтен каплый, шул ук вакытта үзен бизи дә ала. Элеккеге заманнарда кием буенча кешенең җәмгыятьтәге урынын, динен, милләтен, яшәгән җирлеген, азат кешеме яки кол булуын да билгеләп булган. Кием хатын-кызның кияүдә булу-булмавын, ир-атның һөнәре турында сөйләгән. Бүгенге көндә кием мондый үзенчәлекләрен югалтып, бертөрлегә әйләнеп бара.

## Ә мөселманнар ничек киенергә тиеш соң?

Башта иң төп уртак кагыйдәләрне карап китик.

1. Кием хәләл, рөхсәт ителгән акчаларга алынган булырга тиеш (риба, хәмер сату, отышлы уеннар белән акча табарга ярамый).

2. Кием мактану, үз-үзеңне башкалардан өстен күрсәтү, кемнедер кимсетү максатыннан киелергә тиеш түгел.

3. Кием чиста һәм пөхтә булырга тиеш. Мөселман башка кешеләрне тирән ихтирам итеп, мөмкинлеге булса, алар янында пычрак, ертык киемнәр кияргә тиеш түгел. Әгәр Аллаһы Тәгалә бирәүгә мал-мөлкәт бирсә, бу аның киемендә чагылырга тиеш – кием күзне сөендереп торсын, матур булсын (әмма, әйтелгәнчә, мактанырга теләп, бик кыйммәтле киемнәр кияргә ярамый).

Бервакыт Әбү Әл-Әхвәс радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез галәйһиссәлам янына сәләмә киемнәрдән килгән.

– Синең малың бармы? – дип кызыксынган Расүлуллаһ.

– Бар, ий Аллаһының Илчесе!

– Нинди малың бар?

– Минем дөяләрем, атларым, сарыкларым, кәҗәләрем һәм Раббым биргән башка төрле байлыгым бар.

Моны ишеткәч, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Ий, Әбү Әл-Әхвәс, Аллаһы Тәгалә сиңа байлык биргән икән, синдә Аның нигъмәтләренең эзләре күренсен!» – дип әйткән.

## Кием нинди төстә була ала?

Мөселман галимнәре фикеренчә, ак һәм яшел төстәге киемнәрне кию киңәш ителә. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам ак төстәге киемне хуплаган: «Ак киемнәр киегез, чөнки алар иң яхшылары вә мәетләрегезне аларга төрегез». Ә яшел төс Коръәндә искә алына: **«Алар анда (җәннәттә) алтын беләзекләр белән зиннәтләнерләр вә яшел төстә атластан, парчадан кием киярләр»** («Кәһф / Тау куышы», 18:31).

Шулай ук хәдисләрдән Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәламнең кызыл, сары һәм кара төстәге киемнәрне киеп йөрүе дә мәгълүм. Мисал өчен, имам Әт-Табәрани хәдисләр җыентыгында мондый ике хәдис китерелә: «Расүлуллаһ бәйрәм көннәрендә кызыл чапан (өске кием) кия иде», «Мин Пәйгамбәребез өстендә ике сары төстәге кием күрдем». Гайшә анабыз: «Мин Пәйгамбәр галәйһиссәламгә кара төстәге чапан тектем һәм ул аны киеп йөри иде», – дигән.

Галимнәребез мөселманнарга үзләре яшәгән җирлектә таралган төстәге һәм фасонлы киемнәр кияргә киңәш итә, әмма ул шәригать кануннарына туры килергә тиеш.

## Ир-атның киеме нинди булырга тиеш?

1. Кием гаурәтне капларга тиеш. Ирләрдә бу кендектән тезгә кадәр булган өлеш. Әмма монда да билгеле бер җирлектә кабул ителгән кагыйдә һәм гореф-гадәтләрне истә тотарга кирәк. Әгәр бер җәмгыятьтә кыска чалбарлар һәм кыска җиңле күлмәкләр кию кабул ителмәсә, бу рәвешле киенергә кирәкми.

2. Ир-атларга ефәктән тегелгән киемнәр тыелган. Пәйгамбәребез: «Бу дөньяда ефәк кигән (ир-ат), аны Ахирәттә кия алмас», – дигән. Әмма бу ясалма ефәк һәм кешегә берәр тән авыруы аркасында ефәк кием кияргә кирәк булган очракларга карамый.

3. Шулай ук, Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең баш киеменнән йөргәнен риваять иткән хәдисләр бик күп. Ул йә түбәтәйгә охшаш махсус башлык, йә чалма кигән. Шул сәбәпле, ир-атларның башлык киюен күп галимнәр сөннәт дип саный. Хәнәфи мәзһәбе буенча, намазны башлыксыз (түбәтәй, чалма һ. б.) уку киңәш ителми, әмма бу гөнаһ түгел.

## Мөслимәләр киеменә куелган таләпләр

1. Хатын-кызлар киеме шулай ук гаурәтне капларга тиеш. Мөслимәнең гаурәте – бите, беләзекләренә кадәр куллары һәм аяк табаннарыннан кала бар гәүдәсе.

2. Хатын-кызның киеме сыланып торырга, тән төзелешен күрсәтергә тиеш түгел.

3. Шулай ук кием үтә күренмәле, тәннең төсе күренерлек булырга тиеш түгел.

4. Кием артык игътибарны җәлеп итәргә, ягъни бик чуар, бик катлаулы фасонлы булырга тиеш түгел. Мөслимә киеменең төп максаты – тыйнаклык, ә чит-ятларның игътибарын җәлеп итү түгел.

## Кием – Аллаһы Тәгалә биргән зур нигъмәт

Без һәрвакытта да кием, башка нигъмәтләр кебек үк, Аллаһы Раббыбызның безгә биргән бүләге икәнен истә тотарга тиеш. Шул сәбәпле, кием кигәндә, бигрәк тә яңа алынган киемнәрне кигәндә, Аңа рәхмәтләребезне җиткерергә кирәк.

Яңа кием кигәндә түбәндәге доганы укырга була:

اللّهُمَّ لَكَ الحَمْدُ أَنْتَ كَسَوْتَنِيه،
أَسْأَلُكَ مِنْ خَيرِهِ وَخَيْرِ مَا صُنِعَ لَه،
وَأَعوذُ بِكَ مِنْ شَرِّهِ وَشَرِّ ما صُنِعَ لَهُ

Аллаһуммә! Ләкәл-хәмду, әнтә кәсәүтәнииһи, әс-әлүкә мин хайриһи вә хайри мәә сунига ләһү, вә әгузү бикә мин шәрриһи вә шәрри мәә сунига ләһү!

Мәгънәсе: «Аллаһым! Барча мактаулар Сиңа гына, Син миңа бу киемне кидердең. Синнән аның хәерле булуын һәм ясалу максатының да хәерле булуын сорыйм. Аның золымыннан вә аның (киемнең) ясалу максатының золымыннан Сиңа сыенам».

Киенгәндә болай дип дога кылу хәерле булыр:

الحمدُ للهِ الّذي كَساني هذا الثّوب

وَرَزَقَنيه مِنْ غَيْرِ حَولٍ مِنّي وَلا قوّة

Әлхәмду лилләһил-ләзи кәсәәни һәзәс-сәүбә вә разәкънииһи мин гайри хәүлин минни вә ләә куввәтин

Мәгънәсе: «Миңа бу киемнәрне кидергән вә аларны миңа биргән Аллаһыга барча мактаулар булсын, үзем мин көчсез, куәтсезмен».

Шулай ук, киемне уң яктан (уң кул яки аяктан) кия башлау һәм сул яктан сала башлау сөннәт булып тора. Киемне салганда «Бисмиллаһ» дип әйтү күркәм гамәл булыр.

■ Islam-Today

# Эмоция һәм авыру

Узган санда эмоцияләрнең кеше сәламәтлегенә тәэсире турында сөйләшә башлаган идек. Кешеләрнең эчке кичерешләре тышкы яктан нинди авырулар китереп чыгара ала; андый авырулар килеп чыкмасын өчен нинди чаралар күрергә кирәк; әти-әнинең балага карата булган мөнәсәбәте балаларның киләчәгенә, сәламәтлегенә ничек йогынты ясый ала? Болар турында сөйләшүне дәвам итәрбез. Әңгәмәдәшебез – **Алсу Камалова.**



**– Әссәләмү галәйкүм. Бер үк төрле кичерешләр, төрле кешеләрдә төрле авырулар китереп чыгара ала. Бу нәрсәгә бәйле? Әллә бер кеше эмоцияләрне кичерә ала, ә икенче кеше кичермәскә дә мөмкинме?**

– Вәгаләйкүмүссәлам. Аның турында инде сөйләшеп китсәк тә, бераз кабатлап китәсем килә: Аллаһы Тәгалә безне, ягъни кешеләрне төрле-төрле итеп яраткан. Кешеләргә бер-берсен ничек бар, шулай кабул итәргә өйрәнергә кирәк. Мин кешеләрнең яхшы яки яман гамәлләре, аларның гөнаһлары турында түгел, ә аларның табигатьләре, эчке дөньялары турында әйтәм.

Икенче бер мәсьәлә – гөнаһлар. Гөнаһлар да сәламәтлеккә бик нык тәэсир ясыйлар. Һәм без моның турында онытабыз да әле. Кеше гөнаһ кылуы белән үзенең бүгенге көнен генә начарайтып калмый, ул үзенең киләчәгенә дә начар тәэсир ясый. Алай гына да түгел, аның бу гамәле балаларына да тәэсир итәчәк.

Пәйгамбәребез янына бер яшь егет килеп, аннан зина кылырга рөхсәт сорый. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Әгәр бер кеше үз әнисе белән зина кылса, син моны яхшы гамәл дип санар идеңме?» – дип сорау бирә. «Юк, Аллаһының Илчесе», – дип җавап кайтара бу егет. Пәйгамбәребез: «Нәкъ шулай ук калган кешеләр дә, син аларның аналары, кызлары белән зина кылуыңны теләмәсләр иде», – дип җавап бирә. Бу Пәйгамбәребез тарафыннан юкка гына шушы рәвештә тыелмый, чөнки кеше үзе гөнаһ кылгач, аны якыннары, балалары күреп, шуны ук эшли ала, Аллаһы сакласын. Безнең тормышыбызда вак мәсьәләләр була алмый: «Ярар, беркем дә күрмәс әле», – дип әйтә алмыйбыз. Алай була алмый ул. Мин үзем бервакыт балалар бакчасында күңелсез бер вакыйгага тап булдым: бер апа аяк киеменнән коридорда торган аяк киемнәрен таптый-таптый, эчкә таба атлый башлады. Моны мин аяк киемнәре өстеннән дип түгел, ә кешеләр өстеннән үтте, дип аңлар идем. Бөтен кеше дә үзүзен болай тота да алмый. Кемдер үзенә моны рөхсәт итә, ә кемдер юк. Ә бала бит боларның барысын да күрә, кабатлый. Иң башта бу аяк киеме мисалында булачак, аннары сүзләргә, гамәлләргә, эчке кичерешләргә кадәр үсәчәк. Яшь бала чиста булганлыктан, ул бар гамәлне дә дөрес, дип санарга мөмкин, зурлар кылгач, димәк, аны кылырга ярый, дигән уй туа ала. Инде сорауга әйләнеп кайтканда: һәр кеше – бала булсынмы, яшүсмер, олы кеше – тирә ягындагы вакыйгалар белән формалаша. Кеше болай да төрле, шуңа өстәп, тирә-якта барган процесслар кешенең формалашуына шулай ук нинди дә булса тәэсирләр ясамыйча калмый. Шуңа күрә, кемдер бер төрле әйберне әйбәт дип, уңай эмоцияләр, икенчеләре исә шул ук әйберне начар дип, тискәре эмоцияләр кичерә ала.

Моңа өстәп, кеше бу дөньяны төрле органнары аша кабул итә, дип әйтеп киткән идек: кемдер күз белән, кемдер колак (ягъни ишеткәннәренә күбрәк игътибар бирә, дип әйтеп була). Мин үзем күз белән кабул итәм. Ягъни, миңа ошамый торган әйберләр күренсә, ул миңа, минем күрү сәләтемә начар тәэсир итәчәк. Бервакыт минем шулай булды да: күз күремем начарланды. Шулай ук эчтә булганнарны чыгармыйча калдыру, кемнедер бик каты ябыктыра, ә кемнедер, киресенчә, тазарта ала.

**– Кешегә үз өстендә эшләргә кирәкме?**

Без үзебезне ничек бар, шулай кабул итәргә тиеш, дип әйттек. Әмма әгәр кеше үзенең йомшак якларын белә торып: «Ярар инде, мин шулай туганмын, мин шулай яшәрмен», – дип әйтеп, шул өлкәләре өстендә эшләмәсә, бу хакыйкатькә туры килмәячәк. Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә безгә бу йомшак якларыбызны (физик яки психологик яктан җитешсезлекләрне) аларны камилләштерер өчен биргән дә инде. Әгәр дә без кайсы да булса бер өлкәдә уңышка ирешкән кешеләрнең тормышларына карасак, аларның күбесе нинди дә булса бер киртәне җиңеп, алга таба атлый алганнар. Ул киртәләр психологик, физик, мораль яклар да була ала. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: **«Тәхкыйк, Аллаһы бер кавемнең хәлен, ул кавем үзе үзгәрергә теләгәнчегә кадәр үзгәртмәс»,** – дип әйтә бит. Кеше үзе ниндидер хыялар белән болай да яши ала: «Минем симез буласым килми; Минем ялкау буласым килми», – дип, үзенә-үзе көн саен исенә төшереп тора ала. Әмма шәйтан да тик тормый, безнең нәфесебез дә үз эшен башкара. Һәм шулай итеп кеше йомыла башлый. Бу – төшенкелек дип атала. Ә кешеләр төшенкелеккә бирелергә бик тә яраталар. Төшенкелек – ул авыру, ялкаулык – ул авыру. Шәйтан кешеләрнең бу сыйфатын ярата, ул аларны бу авыруга тагы да катырак дучар итәргә тырыша. Әмма Аллаһы Тәгалә Коръәндә үк безгә төшенкелеккә бирешмәскә куша, көч һәм куәт бары тик Аллаһы Тәгаләнең Үзендә икәнен исебезгә төшерә.

Хаҗәр анабыз мисалын карап үтик. Ул чүлдә калганнан соң, су эзләп, бер калкулыктан икенче калкулыкка йөгерә башлады. Су табылуына бернинди дә ишарәләр булмаса да, Аллаһы Тәгаләдән өмет итеп, Аңа тәвәккәл итеп, ул йөгерүен дәвам итте. Ягъни бер эшне башлагач, ул аны ташламады: Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен өмет итеп, шул гамәлендә калды. Бүгенге көндә дә шулай эшләргә кирәк: безнең берәр төрле авыруыбыз бар икән, без Аллаһы Тәгаләгә дога кылырга, Аңа тәвәккәл итәргә, ә аннан соң шул сырхау өстендә эшләргә тиешбез. Һәм әгәр дә без үзебезнең элеккеге халәтебезне яхшыга үзгәртергә теләп, көн саен аз гына булса да бер гамәл кылсак, бу ахыр чиктә зур нәтиҗәгә китерәчәк, ин шә Аллаһ. «Аллаһы Тәгалә аз булса да, дәвамлы булган гамәлләрне ярата», – дип әйткән Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам. Бу ни өчен шулай соң? Без бер тапкыр һәм гомерлек итеп үзгәрә алмыйбыз, без көн саен үзгәрәбез. Акрын гына йә яхшыга, йә яман якка таба. Шулай итеп, көн саен үзебезне яхшы якка үзгәртеп, үзебез дә үзгәрәбез, тирә-ягыбызның да үзгәргәнен сизәрбез. Безгә карап балаларыбыз да үзгәрә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: безнең тормышыбызның ахыры матур булсын иде. Без барыбыз да Аллаһы Тәгалә хозурына кайтучы кешеләр. Әмма аңа кайту да матур булырга тиеш. Әгәр кешегә берәр төрле авыру килсә, Аллаһы Тәгалә ул авыруны гөнаһларыбызга кәффарәт итеп кылса иде. Әмма кеше авырып китсә, моның турында оныта башлый. Ул Аллаһыдан сабырлык һәм авыруы өчен савап сорарга да оныта. Әмма авырудан савыккач та, кеше барыбер бу дөньяда мәңге калмаячак. Берәр төрле финанс проблемалар туса да, кеше тизрәк моннан чыгарга тели башлый. Байый да, мәңге каламы соң дөньяда? Юк бит, без көн саен Аллаһы хозурына якынлашучылар гына. Аллаһы Тәгаләдән савап өмет итеп, Аның рәхмәте белән гел сәламәт, төшенкелеккә бирелмичә яшәргә насыйп булсын.

**– Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт, әссәләмү галәйкүм.**

– Вәгаләйкүмүссәлам.

■ **«Хозур ТВ»**

# ХИҖАБНЫҢ ӘҺӘМИЯТЛЕЛЕГЕ

«Хиҗаб» гарәп теленнән «бөркәнчек», «бөркәнү», «каплау» дип тәрҗемә ителә. Шәригатьтә исә «хиҗаб» – хатын-кызның билгеле бер таләпләргә һәм шартларга туры китереп, тәнен каплавы.

Әйткәнебезчә, тәнне каплаган кием «хиҗаб» булып саналсын өчен, Ислам динендәге кайбер таләпләрне сакларга кирәк. Тәннең кайбер өлешләрен генә каплаган гадәти кием хиҗаб булып саналмый. Алга таба без хиҗабның өстенлеге, аңа карата булган таләпләр һәм хатын-кызга тәннең кайсы өлешләрен капларга тиешлеге турында сөйләрбез.

Мөхтәрәм җәмәгать, иң элек хиҗабның өстенлеген карап үтик. Беренчедән, хиҗаб – Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның Илчесенә буйсынуны белдерә.

Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Аллаһы вә Аның Расүле бер нәрсә хакында хөкем итсәләр, бернинди мөэмин ир вә мөэминә хатын бу хөкемне читкә куеп, үзләре теләгәнне ихтыяр итәргә лаек булмас, бәлки Аллаһы вә Расүлнең әмерләрен тоту фарыз буладыр. Әгәр берәү Аллаһы вә Расүлнең әмерен тотмыйча, нәфесе теләгәнчә, яки динсез кешеләргә ияреп эш кылса, тәхкыйк, ул кеше ачыктан-ачык адашты».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:36

Аллаһы Тәгалә хатын-кызга бит һәм беләзеккә кадәр кулларыннан кала тәннең бөтен өлешләрен дә капларга әмер кыла. Коръәндә болай дип әйтелә:

**«Мөэминә хатыннарга әйт: карарга ярамаган нәрсәдән күзләрен йомсыннар вә фәҗерләрен зинадан сакласыннар һәм кул белән йөзләреннән башка булган зиннәт урыннарын ачмасыннар ...».**

«Нур», 24:31

Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Хатын-кыз (аның тәне) тулысынча гаурәт булып тора (чит ирләргә мөнәсәбәтле)», – дип әйткән (Тирмизи).

Икенчедән, хиҗаб гыйффәтлекне күрсәтә, хатын-кызның намусын саклый, ягъни хиҗаб хатын-кызны начар ниятле карашлардан саклап, мөслимәнең тыйнаклыгын күрсәтә. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

**«Ий, пәйгамбәр галәйһиссәлам, үз хатыннарыңа, вә кызларыңа һәм башка мөэминә хатыннарга: «Бер эш белән урамга чыксалар, бөркәнчекләрен башларына салсыннар, ягъни барча әгъзаларыгызны каплый торган зур әйбер белән төренеп чыгыгыз», – дип әйт. Шулай төренеп чыгулары аларның хөр вә мөэминә хатын икәнлекләрен белергә якынрак буладыр. Итагать итүче мөэминә хатыннарны Аллаһы ярлыкаучы вә аларга рәхмәт итүче булды».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:59



Өченчедән, хиҗаб – ул чисталык билгесе. Хиҗаб кию күңелне яман һәм гөнаһлы уйлардан чистарта. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

**«... Әгәр пәйгамбәр хатыннарыннан берәр нәрсә сорасагыз, пәрдә аркылы сорагыз, әнә шулай соравыгыз сезнең күңелләрегезгә дә, аларның күңелләренә дә пакьлерәктер ...»**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:53

Шул ук сүрәнең икенче бер аятендә болай дип әйтелә:

**«... ят ирләргә җавап биргәндә тавышларыгызны нечкәртеп, йомшак сөйләмәгез, чөнки нечкә тавыш белән йомшак сөйләсәгез, күңелләрендә шәһвәт яки яманлык чире булган ирләр сездән өметләнерләр, вә аларга тавышыгызны нечкәртмичә яхшы сүз әйтегез».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:32

Хөрмәтле мөселманнар, игътибар итегез! Әлеге аятьләрдә Пәйгамбәр галәйһиссәламнең хатыннарына мөрәҗәгать ителсә дә, барлык мөслимәләр дә моннан үрнәк алырга һәм шул рәвешле гамәл кылырга тиешләр.

Дүртенчедән, хиҗаб – тәкъвалык билгесе.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

**«Ий Адәм балалары! Без сезгә гаурәтләрегезне каплар өчен һәм матурлык буларак киемнәр яраттык, әмма тәкъвалык киеме сезнең өчен хәерлерәктер...»**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:26

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бер хәдисендә: «Хатынны дүрт сыйфатына карап сайлыйлар: байлыгына, нәселенә, чибәрлегенә һәм тәкъвалыгына. Тәкъва булганын сайлагыз, юкса кыен хәлдә калырсыз», – дип киңәш бирә (Бохари җыентыгыннан).

Күргәнебезчә, хатын-кызның тәнен каплау турындагы шәригать хөкеме ирләргә тормыш иптәшен сайлаганда, аның тышкы гүзәллегенә алданып, хата эшләмәскә ярдәм итә, Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең киңәшләрен тыңлап, өстен рухи сыйфатларга ия булган хатынны сайларга өнди.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, инде алга таба хиҗабның шартларын билгеләп үтик. Коръәни Кәримдә һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең хәдисләрендә дә хатын-кыз киеменә карата булган таләпләр ачык билгеләнгән. Ул түбәндәге шартларга туры килергә тиеш:

1. Бит һәм беләзеккә кадәр кулларыннан кала тәннең барлык өлешләре дә капланырга тиеш.

2. Кием артык игътибарны җәлеп итәргә тиеш түгел, ягъни купшы булмаска тиеш.

3. Кием үтә күренмәле булмаска тиеш. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Киенгән, ләкин шул ук вакытта ялангач булган, йөргәндә селкенеп йөрүче һәм шулай итеп ирләрне үзләренә каратучы хатын-кызлар җәннәткә кермәячәкләр һәм хәтта хуш исен дә иснәмәячәкләр», – дип әйткән (Мөслим җыентыгыннан).

4. Кием киң булырга тиеш, ягъни тәнгә сыланып торырга тиеш түгел.

5. Киемнән хушбуй исе килергә тиеш түгел.

6. Киемнәре башка дин тотучыларның киемнәренә охшарга тиеш түгел.

7. Кеше әлеге кием белән халык арасында танылуны максат итеп куярга, ягъни киемнең төсе яки ниндидер бизәкләре белән халык арасында аерылып торырга тиеш түгел.

Дин юлыннан барган хатын-кыз хиҗабны зур канәгатьләнү һәм тыныч күңел белән кабул итә, аның кирәкле нәрсә икәненә ышана, чөнки бу – Аллаһы Тәгаләнең әмере: ирләрнең кушуы яки аларның теләгенә буйсыну гына түгел.

Үзенең төп максаты – хатын-кызның гыйффәтен саклау белән беррәттән, хиҗаб тагын бер күркәм вазифа башкара. Ул хатын-кызның гаурәтен каплый. Гаурәтне каплау намаз укуның да бер шарты булып тора. Шуның өчен бу мәсьәләдә бик игътибарлы булырга кирәк. Хатын-кызларның гаурәте нәрсәдән гыйбарәт соң?

1. Мөслимәнең ят ирләр алдында йөзеннән, беләзеккә кадәр кулларыннан һәм аяк табаннарыннан башка бөтен тәне гаурәт була.

2. Бүтән мөселман хатыннар алдында мөслимә тәненең кендектән алып тезләренә кадәр булган өлеше гаурәт булып санала; ә диндә булмаган хатыннар алдында гаурәт нәкъ тә чит ирләр алдында булган кебек.

3. Мәхрәм туганнары алдында хатын-кыз кулларын, чәчен, балтырларын һәм колакларын ачарга мөмкин. Аның тәненең бу өлешләрен мәхрәмгә күрергә тыелмаган.

Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең хатыннары ак, кызыл, соры һәм кара төстәге киемнәрне дә кигәннәр. Мөслимә үзе яшәгән җирлектә күзгә бик үк ташланмаган һәм аны башкалар арасыннан аерып тормаган төстәге кием кисә, хәерлерәк булыр.

Хатын-кыз үз-үзен җиңеп, динебез кушканча киенеп, балаларын да шушы үрнәктә тәрбияли икән, бу – зур батырлык, үзенең сафлыгын, дәрәҗәсен, бәясен аңлый һәм саклый белгән кешенең эше. Балаларыбыз да дини тәрбияне кечкенәдән үзенә сеңдереп үссә, җәмгыятебез төзек булыр, бозыклык, гөнаһлардан ерак торыр иде.

**■ ТҖ мөселманнары диния нәзарәтенең Дәгъват бүлеге**

# Утырып йокласаң тәһарәт бозыламы?




**Сорау: Әгәр кеше бернәрсәгә дә терәлмәгән килеш, утырган хәлендә йокыга китсә, аның тәһарәте бозыламы?**

**Җавап:** Әгәр кеше идәнгә арт саны белән нык берегеп утырса, бу һава чыгуны тоткарлый ала. Бу очракта аның тәһарәте бозылмый. Әгәр дә инде кеше берәр нәрсәгә сөялеп утырса яисә нәрсәгәдер терәлеп йокыга китсә, һәм ул терәлгән әйберне алып, ул егыла калса, бу очракта инде аның тәһарәте бозылган булып санала. Киресенчә булганда, тәһарәт бозылган булып саналмый. Әлеге фикергә каршы башка фикерләр булса да, ләкин фәтвалар нәкъ менә шушы фикергә нигезләнеп чыгарылганнар. Шуны да истә тотарга кирәк: бүгенге көндә күп ризыкларның шактый майлы булуын исәпкә алганда, йокыдан уянганнан соң һәрвакытта да тәһарәт алсак, хәерлерәк булыр. Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

■ **ТҖ мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин**

# Тыелган нәрсәне ялгышлык белән хәләл дип әйткән кеше мөртәт буламы?



**Сорау: Әгәр кеше ялгышлык белән тыелганны хәләл дип атаса, ул мөртәт (динне калдырган кеше) буламы? Әгәр кеше динен ташласа, ул ничә талак белән аерылган булып санала?**

**Җавап:** Әгәр дә кеше ялгышлык белән харам нәрсәне хәләл дип атаса, ул мөртәт, ягъни динен ташлаган кеше булып саналмый. Шуны искәртеп үтәргә кирәк: аерылу (талак) мәсьәләсе берничек тә мөртәтлек (диннән чыгу) белән бәйле түгел. Әгәр кеше динен ташласа (Аллаһы сакласын), бу очракта талак булмый, бары тик әлеге кешенең никахы бозыла. Әгәр бу кеше янәдән дингә кайтса, ягъни Ислам динен кабул итеп, мөселман булса, бу очракта ул хатыны белән янәдән никах укытып, аның белән яшәвен дәвам итә. Никахның бозылуы талак хокукы куллануны аңлатмый, ягъни әгәр кеше яңадан никах укыта икән, әлеге кешедә өч тапкыр талак кылу хокукы саклана. Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

■ **ТҖ мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин**

# Корьәнне нинди ешлык белән уку дөрес?

**Сорау: Ислам буенча дөрес булсын өчен, Корьәнне нинди ешлык белән укырга кирәк? Корьәнне елга бер мәртәбә уку җитәме?**

**Җавап:** Кайбер галимнәр Корьәнне бер көн эчендә укып чыгу хәерле түгел дигән фикерне дә әйтәләр. Корьәнне олылау ниятеннән, өч көннән дә иртәрәк хәтем кылынмый.

Корьәнне елга бер мәртәбә хәтем чыккан кеше, Корьәнне ташлаган булып саналмый. Җәйге вакытта иртәнге якта, ә кышын төн алдыннан хәтем кылу (Корьән уку) мөстәхәб гамәл санала. Кешеләрнең бергәләп кычкырып (төрлесе Корьәннең төрле урыныннан) укулары мәкруһ, чөнки бу очракта кеше ишетми һәм игътибар белән тыңламый. Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

■ **ТҖ мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин**

# Азаннан соң нинди дога кылына?



**Сорау: Әгәр мин азан әйткәннәрен ишетсәм, аны кабатларга кирәкме? Һәм азанны тыңлаганнан соң, нинди дога кылырга кирәк?**

**Җавап:** Мөәзин артыннан азанны кабатлап әйтү сөннәт гамәл санала. Хәдисләрдә мөәзин артыннан кабатлаган кешегә азан әйтүчегә ирешкән кадәр савап язылыр, дип әйтелә. Азан тәмамланганнан соң түбәндәге дога кылыныр:

**Аллаһуммә раббә һәәҙиһид-дәгъвәтит-тәәммәти вәс-саләәтил-каа'имәһ. Әәти Мүхәммәдәнил-вәсииләтә вәл-фәдыйләтә вәддәраҗәтәл-гаалийәтәр-рафиигәһ. Вәбъгәҫһү мәкаамәм-мәхмүдәнил-ләҙии вәгадтәһү вәрзүкнәә шәфәәгатәһү йәүмәл-кыйәәмәһ. Иннәкә лә түхълифүл-мигаад.**

**Мәгънәсе:** «Әй, шушы камил азанның һәм вакыты кергән намазның хуҗасы, Аллаһы Тәгалә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ярдәмне, артыклыкны һәм югары дәрәҗәне бир. Шулай ук аны Үзең вәгъдә кылган мактаулы урынга ирештер һәм Кыямәт көнендә аның шәфәгатен безгә насыйп ит. Дөреслектә, Син Үз вәгъдәңә хилафлык кылмыйсың».

■ **«Гыйбадәте Исламия» китабыннан**

# Ятлаган сүрәләр онытылса, гөнаһ буламы?



**Сорау: Берәр кеше Корьәннән нәрсәдер булса өйрәнеп, ә аннан соң онытса, аңа гөнаһ языла, дип ишеткәнем бар. Бу шулаймы? Әгәр мөсхаф саклауга бирелгән булса, аннан уку ярыймы?**

**Җавап:** Яттан (күңелдән) укуга караганда Корьәнне мөсхафтан (ягъни нәкъ гарәп телендә язылган/бастырылган Корьән китабыннан) уку хәерлерәк. Әгәр кеше Корьәннән нәрсәдер булса өйрәнеп, бераздан шуларны онытса, ул гөнаһлы була. «Онытты» дигәндә кешенең Корьәнне мөсхафтан да укый алмавын аңларга кирәк. Корьәнне сиңа әманәт буларак саклауга тапшырылган мөсхафтан укымау хәерле. Әгәр мөсхаф көч кулланып (ирексезләп) алынса, иҗмаг буенча, аннан уку ярамый. Балигъ булган кешедән мөсхафны уку нияте белән сорап торсалар, аннан уку рөхсәт ителә. Әгәр ул балигъльккка ирешмәгән булса, уку киңәш ителми. Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

■ **ТҖ мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин**

# Диния нәзарәте Пленумының



Җөмәдәл-әүвәл аеның 11 нче көнендә (17 гыйнвар), Болгар Ислам академиясендә ТР мөселманнары Диния нәзарәте Пленумы утырышы уздырылды. Утырышта Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның урынбасарлары, ТР баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Спас районы башлыгы Камил Нугаев, шулай ук бөтен республикадан имам-мөхтәсибләр һәм мөфтият эшчәнлегенең барлык юнәлешләре һәм оешмалары җитәкчеләре катнашты.

Көн тәртибенә ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм аның оешмаларының 2018 елдагы эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм 2019 елга планнар, шулай ук «ТР мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйблары тарафыннан гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар үткәрү турында Нигезләмә»не раслау турындагы сораулар куелды.

Пленумда катнашучыларны Болгар ислам академиясендә Спас районы башлыгы Камил Нугаев сәламләде. Ул Татарстан җитәкчелеге – ТР Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханова һәм Минтимер Шәрип улы Шәймиевка борынгы Болгар шәһәрен торгызу, Спас районында мөселман инфраструктурасы үсешенә керткән өлешләре өчен рәхмәтен белдерде. Моннан тыш, ул ТР мөфтие Камил хәзрәткә мөселман мәгариф системасы өлкәсендә куйган тырышлыгы һәм Болгар ислам академиясе эшчәнлегендә катнашканы өчен рәхмәт сүзләре җиткерде. Үз чиратында, Татарстан мөселманнары башлыгы аңа, мөфтиятнең күпсанлы чараларын оештыруда ярдәм күрсәткәне өчен, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең истәлек медален тапшырды.

## Эшчәнлеккә нәтиҗәләр ясалды

Алга таба мөфти нәзарәтнең 2018 елдагы эшчәнлек йомгакларына һәм иң уңышлы нәтиҗәләргә багышланган доклад белән чыгыш ясады. 2018 елда ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм мөхтәсибәтләр тарафыннан дәгъват, исламның хакыйкый кыйммәтләрен яңарту, пропагандалау һәм тарату, шулай ук татар җәмгыятендә исламның чәчәк атуын һәм татар өммәтенең асылына кайтуын күздә тоткан милли үзенчәлекне саклау өлкәсендә шактый башлангычлар гамәлгә ашырылуын билгеләп узарга кирәк. Алар арасында бөтен Россия ислам җәмәгатьчелеге өчен әһәмияткә ия булган казанышлар да бар.

Үзенең чыгышында Камил хәзрәт 2018 елның Татарстан Республикасында бөек татар дин галиме һәм мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани елы дип игълан ителүен искәртеп: «Мәрҗанинең алты томлык сайланма хезмәтләр җыентыгын бастырып, әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итеп, аның иҗатын өйрәнүгә багышланган фәнни эзләнүләрне һәм татар, рус, инглиз телләрендә документаль фильмны дөньяга чыгарып, шулай ук барлык мөхтәсибәтләрдә фәнни форумнар, иҗади бәйгеләр, спорт чаралары һәм тематик кичәләр, очрашулар оештырып, Диния Нәзарәте мәгърифәтченең исемен мәңгеләштерү эшенә фундаменталь өлеш кертте», – диде.

Моннан тыш, Мәрҗанинең татар халкының милли асылын саклау буенча тезислары («Өч төрле әйбер диндә булмаса да, динне саклый. Алар: милли тел, милли кием һәм милли гореф») Диния Нәзарәтенең татар телен саклау һәм өйрәнү буенча эшчәнлеген көчәйтүдә мөһим нигез булып хезмәт итте.

Бу өлкәдә иң мөһим казаныш булып республика мәчетләрендә татар телен өйрәнү буенча курслар оештыру тора. Нәтиҗә буларак, татар телен өйрәтү буенча бушлай курслар 900гә якын кешене һәм 20 мәчетне колачлады.

Моннан тыш, мөселман мәгариф системасы алдында «татар зыялысы» катламын тәрбияләү максаты куелды. Әлеге бурычны үтәп, Әлмәт мөхтәсибәтендә «Нур» татар мәктәбе, ә Балтачта малайлар өчен татар телендә тәрбия бирә торган «Ярдәм» пансионаты ачылды. Татарстан мәдрәсәләрендә укытуның татар телендә алып барылуын да ассызыклап үтү кирәк. Нәзарәтнең традицион ислам кыйммәтләрен пропагандалау буенча мөһим проекты булган «Хозур TV» беренче мөселман телеканалын эшләтеп җибәрү, шулай ук мөфтияткә БМО консультатив статусы бирелү, социаль эшчәнлекне һәм яшьләр сәясәтен көчәйтү дә мөһим казанышлар буларак тарихка кереп калды.

Нәшрият эшчәнлегендә дә зур алга китеш күзәтелде: Әбү Хәнифә, Матуриди, Тахави, Р. Фәхретдин, К. Насыйри, Ә. Максуди, Г. Карабаши һ. б. классик мөселман һәм татар дин галимнәре хезмәтләре әзерләп бастырылды. «Хозур» нәшриятында гомуми тиражы 210 мең данәдән артык, барлыгы 53 исемдәге китап дөнья күрде.

Шулай да, Камил хәзрәт билгеләп узганча, ТР мөселманнары Диния нәзарәте 2018 елда горурланырлык иң зур казанышларга – татар һәм рус телләрендә Коръән тәфсирләрен басмага әзерләү эшенә иреште. Мөфтият Россиядә Коръәнне дөрес аңлау нигезендә мөселман хокукын үстерү өчен заманча фундаменталь база булдыру буенча эшләрне төгәлләү алдында тора.

– Халыкара стандартлар буенча Коръән бастыру, татар халкында Коръән бастыру традицияләрен яңарту, татар һәм рус телләрендә

# 2019 елда беренче утырышы




тәфсирләр әзерләү, Коръән-хафизлар тәрбияләү – Россия өммәте өчен терәк булган әлеге бурычларны мөфтият 2018 елда уңышлы башкарды һәм яңа елда да дәвам итәчәк. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Президиумы карары белән 2019 ел Тәфсир елы дип игълан ителде, – диде хәзрәт.

## 2019 елга төп максатлар

Шуның белән бәйле рәвештә, мөфти Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең 2019 елга төп максатларын һәм эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләрен билгеләде: тәфсирләр бастыру; татар дин галимнәре, Коръән тәфсирләре авторлары Шәйхелислам Хәмиди һәм Морад Рәмзи, шулай ук Ризаэтдин Фәхретдин һәм Мөхлисә Бубыйларның юбилейлары уңаеннан чаралар үткәрү. Ул имамнарга һәм Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте структуралары җитәкчеләренә әлеге мөһим юбилей даталарына 2019 елда эшчәнлек алып барганда игътибар юнәлтергә һәм агымдагы эш юнәлешләрен көчәйтергә чакырды. Үз чыгышы ахырында мөфти имамнарга түбәндәге Коръән аятен искә төшереп үтте: **«Өммәтләргә хөкемнәребезне аңлатыр өчен, Без һәр пәйгамбәрне үз кавеменең теле белән сөйләшә торган итеп җибәрдек. Аллаһы теләгән кешене юлдан яздырыр, теләгәнен һидаятькә ирештерер. Ул – Җиңелмәс, Хикмәт Иясе»** («Ибраһим», 14:4). Шулай итеп, мөфти хәзрәт ассызыклаганча, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте үз эшчәнлеген туган телебездә, үз гореф-гадәтләребезне, үз бабаларыбызның бәһасез рухи мирасын саклап алып бару белән тыгыз бәйләнештә дәвам иттерәчәген белдерде.

## «Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар үткәрү турында Нигезләмә»

Алга таба чыгыш ясау өчен сүз Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллинга бирелде, моннан тыш ул бертавыштан Пленум утырышы сәркатибе итеп сайланган иде. Аның чыгышы «ТР мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйблары тарафыннан гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар үткәрү турында Нигезләмә»не раслау мәсьәләләренә багышланды. Исегезгә төшерәбез, Пленум утырышына кадәр документка өстәп кертелгән пунктлар буенча ике көнлек фикер алышулар узды. 15–16 гыйнвар көннәрендә республиканың барлык 48 мөхтәсибәте башлыклары мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә, голәмәләр һәм казыйлар катнашында имамнар өчен ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан әзерләнгән Нигезләмә турында фикер алышу һәм аңа кертелгән үзгәрешләрне раслау өчен җыелды. Рөстәм хәзрәт ассызыклаганча, асылда, традицион исламны саклау механизмы булып торган Нигезләмәне камилләштерү өстендә эшләгәндә, гакыйдә һәм хәнәфи мәзһәбе буенча җиде мөселман галименең, шул исәптән, 4 борынгы галимнең классик хезмәтләре файдаланылды.

– Мин әлеге Нигезләмәдән аерым пунктка игътибар юнәлтергә телим: «Коръән аятьләре һәм хәдисләргә мөстәкыйль рәвештә аңлатма бирергә бары шәригать белемнәрен үзләштерүнең иң югары дәрәҗәләренә ирешкән мөҗтәһидләр генә хокуклы. Әлеге дәрәҗәдәге белемнәргә ия булмаганнар мөкаллидләр булырга, ягъни имам-мөҗтәһидләргә иярергә тиешләр», – дип билгеләп үтте Рөстәм хәзрәт һәм хаталы шәригать карарлары, фәтвалар чыгарудан ерак торырга чакырды.

Имамнар эшчәнлеген стандартлаштыра торган Нигезләмә, Рөстәм хәзрәт сүзләренә караганда, «дини эшчәнлекнең проблемалы ишекләрен ябa». Документ 2014 елда әзерләнеп, имамнар эшендә кулланыла башлады, әмма Татарстанда дини һәм иҗтимагый өлкәдәге көнүзәк вәзгыятьне исәпкә алып, төзәтмәләр кертү зарурияте килеп чыккан саен, шул исәптән, 2018 ел дәвамында да, өстәмәләр кертү өстендә эш алып барылды. Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү өчен Диния Нәзарәтендә, составына шәригать өлкәсе белгечләре, казыйлар, голәмәләр кергән эшче төркемнәр булдырылды. Нигезләмәдә җомга намазларын, гает намазларын, мәетне озату, исем кушу йолаларын, ифтарлар уздыру, никах һәм талак тәртипләре һ. б. турындагы бүлекләргә бүгенге чынбарлыкны исәпкә алып үзгәрешләр кертелде һәм ул утырышта расланды.

Үзенең нәсыйхәт сүзләре белән дин әһелләре каршында Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев та чыгыш ясады. Тормышка ашырылган эшчәнлек буенча шулай ук Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте структуралары җитәкчеләре хисап тотты: Казыйлар шурасы, Голәмәләр шурасы, «Хозур» нәшрият йорты, «Татарстан Республикасы Вакфы» фонды, «Хәләл» стандартлар буенча комитет һәм «Зәкят» хәйрия фонды, шулай ук мөфти урынбасарлары Рафикъ хәзрәт Мөхәммәтшин һәм Мансур хәзрәт Җәләлетдин үз өлкәләре буенча чыгыш ясады.

■ dumrt.ru

# Исламда тәрбиягә бала алу кагыйдәләре



Бүгенге көндә гаиләгә караган четерекле мәсьәләләр шактый күп. Шундыйларның берсе – тәрбиягә бала алу. Ислам дине тәрбиягә бала алуны рөхсәт итәме? Бүгенге мәкаләбездә шуның турында тәфсилләбрәк сөйләрбез.

Раббыбыз Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәрим китабында, расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәдисләрендә ятимнәрнең хакы турында әйтеп узалар. Ятимне тәэмин итү, аны карау һәм шул ятимне үзенә алып тәрбияләү – ул бик саваплы, бик әҗерле. Һәм, әлбәттә, Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә моны рөхсәт иткән. Бу күренеш Расүлебез галәйһиссәлам заманында ук булган, бүгенге көндә моның белән шөгыльләнүче кешеләргә Аллаһы Тәгалә әҗерләрен, бәрәкәтләрен, уңышларын бирсен, чөнки ятим балаларны карау, тәрбиягә алу, тәэмин итү – ул бик саваплы, зур дәрәҗәле гамәл.

### Бала кем фамилиясен алырга тиеш?

Тәрбиягә алганда, берничә төрле мәсьәләгә ачыклык кертергә кирәктер. Мәсәлән, Пәйгамбәребез: «Үзегезне фәлән-фәлән нәселдән дип, ялганлап әйтмәгез», – дип әйткән. Әмма бу хәдисне дөрес итеп аңларга кирәк. Бу, иң беренче чиратта, безнең гүзәл затларыбызга да кагыла. Аларның кайберләре: «Мин кияүгә чыккач, үземнең фамилиямдә калам, алыштырмыйм. Расүлебез шулай кушкан», – дип әйтәләр. Әмма, кияүгә чыгып, хатын-кыз үзенең әтисен ирнең әтисенә алыштырмый, моны һәркем дә бик яхшы аңлый. Ир-ат та үз хатынына: «Минем хатыным өчен минем әти генә бар», – дип әйтми. Барлык якыннары да аның кыз фамилиясен дә, аның әти-энисен дә бик яхшы беләләр.

Ә менә балаларга килгәндә, ул бераз катлаулырак мәсьәлә, дип әйтер идем. Мәсәлән, сез сабый чагында бер баланы алдыгыз, ди. Расүлебез әтиләрнең исемен үзгәртү тыела, дип әйтте. Шуңа күрә, әгәр дә ул Габдулла улы булып, мин Рөстәм хәзрәт булярак, үземә тәрбиягә алсам, документларда аны Рөстәм улы дип яздыра алмыйм, ул үз әтисенең малае булып кала. Барлык төр таныклыкларда да аның исеме һәм үз әтисенең исеме язылыр. Моның турында Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтеп уза: **«Тәрбияләр өчен үз гаиләгезгә алган ир балаларга аталарының исеме белән дәшегез».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:5

Шулай ук, бала үсеп җиткәч: «Улым/кызым, без сине тәрбиягә алдык», – дип әйтәсе була. Бала күңеленә җәрәхәт булмасын өчен, аны бу сөйләшүгә алдан ук әзерләргә кирәк. Ничек кенә булмасын, тәрбиягә алган ата-ана үги булып саналачак. Бала хөрмәт йөзеннән барыбер аларга әти-әни дип дәшә ала. Әмма баланың үз әти-әнисенең дә исемнәре билгеле булырга тиеш. Бала үскәч, боларны белергә, ә тәрбиягә алган ата-ана моны аңларга тиеш.

### Уллыкка алу һәм опекунлык

Баланы тәрбиягә алу дигәндә ике төрле төшенчә бар. Беренчесе, уллыкка, кызлыкка алу. Икенчесе – опекунлык. Дин ягыннан кайсы дөрес соң, дип тә сорыйлар. Дин күзлегеннән бу болай карала: баланы уллыкка/кызлыкка алу дип аталамы, тәэмин итү яисә попичение дип саналамы ул – баланы үзеңә алсаң да, баланың барлык кәгазьләрендә аның әти исемнәре сакланырга тиеш. Баланы улым, кызым дип үстерсәк тә, без аны үзебезгә тәрбиягә алганны онытмаска тиеш.

### Ятимнәрнең малы – кагылгысыз

Монда тагын бер мәсьәләгә игътибар итәргә кирәк. Мәсәлән, дәүләт тәрбиягә алган балалар өчен акчалата ярдәм күрсәтергә мөмкин. Коръәни Кәримдә Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә ятимнәрнең малларын үзләштермәскә боера. Әгәр дә баланы начар ният белән, ягъни: «Хөкүмәт балага акча күчерәчәк, ул акчаны үземә тотачакмын», – дип алсак, яки баланың мирасы күп булып, аны да үзебезнеке итәргә тырышып кына, баланы үзебезгә алсак, бу гөнаһлы эш булып санала. Аллаһы Тәгалә моны Үзенең китабында тыйды, кардәшләрем. Киресенчә, без баланың малын баланың үзенә тотарга тиешбез. Мәсәлән, балага ай саен пенсия рәвешендәме, дотация рәвешендәме акча килеп тора икән, без аны шушы баланың хаҗәтләренә тотарга тиешбез. Бу фикерләрне дөрес аңларга кирәктер: бала безнең белән бергә тора, шуңа күрә дә ул акчаларны газ өчен, ут өчен түләү ярый. Хөкүмәт тә бүгенге көндә бу мәсьәләгә җитди карый: балага дип түләнгән акча аның киләчәге, аның тәрбиясе өчен тотыламы? Аллаһы Тәгалә Үзе сакласын, баладан качып, ул акчаларны башка өлкәләрдә тоткан ата-аналар да бар бит (азарт уеннарга, хәмер эчемлекләргә). Бу зур гөнаһ һәм без моннан ерак булырга тиешбез.

### Тәрбиягә алганда мәхрәм мәсьәләсе

Баланы сабый чакта ук алсаң, ул әле бәләкәй була һәм шул вакытта тәрбиягә алган әни аны имезсә, ул сөт баласы дип аталыр. Шуңа да бу очракта мәхрәмлек мәсьәләсе, ягъни гаурәтне каплау кебек әйберләр җиңелрәк була. Бу турыда Коръәндә дә әйтелеп китә. Әгәр дә без баланы алып кайтып, имезсәк, аңа калган балаларга караган кебек карарга, шулай ук киендерергә кирәк. Ул кыз бала икән, димәк, яулыксыз йөри ала. Ир бала икән, үги сеңелләрен яулыксыз күрә ала. Сөт балалардан бу гаурәт кебек мәсьәләләр төшеп кала.

Әгәр дә без тәрбиягә бераз зуррак баланы алсак, бу вакытта гаурәт мәсьәләсенә җитди итеп карарга кирәк. Киенү, гаурәт мәсьәләләре сакланган булырга тиешләр. Шуңа күрә, дин ягыннан караганда, гаурәт, киенү, мәхрәм мәсь-әләләрендә проблема тумасын өчен, имчәк баланы алсагыз яхшырактыр.

Шундый очраклар да булгалый, мәсәлән, бала тудыру йортында яткан вакытта, бер ананың сөте булмыйча, икенче бер хатын аның баласын имезергә мөмкин. Кайбер галимнәр фикеренчә – бер, ә кайберләренеке буенча ике һәм аннан күбрәк тапкыр имезгән бала сөт баласына әйләнә. Һәм бу ананың үз баласына сөт баласы мәхрәм була. Ягъни әгәр бу ананың үз баласы кыз, ә ул имезеп торган бала ир булса, үскәч, аларга никахлашырга тыела.

## Баланың нәсел-нәсәбе

Интернаттан балалар алганда, һәрвакытта да баланың әти-әнисе турында, кем ул, нинди нәселдән икәне турында төгәл мәгълүматлар табып булмый. Бу очракта ни эшләргә соң?

Мондый проблемалар бар, әлбәттә. Элегрәк заманнарны карасак, безнең дәүләтләребездә дә, башка күрше дәүләтләрдә дә балалар йорты булмаган. Берәр баланың ата-анасы, Аллаһы сакласын, вафат була калса, ятим балаларны якын туганнары үзләренә ала торган булганнар. Шулай итеп, һәр ятим бала үз туганнарында ризык тапкан. Татарларда элек-электән мондый йортлар булмаган дип әйттек, чөнки әгәр дә безнең бер туганыбыз ятимнәр йортында тәрбияләнә икән, бу безнең нәселгә тап төшерү булып торган. Бүген дә шулай булсын иде, минем бер киңәшем: ятимнәр йортында тәрбияләнә торган якын кешеләребезне анда калдырмасак иде. Аларны үзе-безгә алып, туганлык җылылыгын бүләк итсәк, хәерле булыр иде.

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

# Кыйммәтле ташларның серләре

Дөньяда бик күп кызыклы ташлар бар. Ләкин без монда бөтен җирдә очратырга мөмкин булган гади ак ташлар турында сөйләшмибез. Кайбер ташларны без кыйммәтле ташлар дип йөртергә гадәтләнгән. Ә ни өчен без аларны шулай дип атыйбыз соң? Сезнең берәр кайчан бу турында уйлап караганыгыз булдымы? Юк, алар акча ягыннан кыйбат булганы өчен түгел. Халыкка андый исем белән кереп калса, кыйбат булган бөтен әйбер дә кыйммәтле булыр иде. Һәм аларны тышкы матурлыклары өчен дә алай атамыйлар. Кешелек өчен ул ташларның эчке сыйфатлары элек-электән мөһим булган, шуңа да алар кыйммәтле ташлар дип атала башлаганнар.

## Сердолик ташы



Сердолик – сары, кызгылт сары, кызыл, кайбер очракларда ак һәм соры төстә була торган таш. Бу таш дәрәҗәсе ягыннан үз заманында алмаз, энҗе һәм зөбәрҗәт (изумруд) кебек ташлардан соң килә торган булган. Аннан соң гына якутлар, алтын һәм көмешләр килгән.

Бүгенге көндә кыйммәте ташларны берничә төргә бүлеп карыйлар:

– кыйммәтле ташлар;

– ярымкыйммәтле ташлар;

– кирәк-ярак өчен кулланыла торган ташлар һ.б.

Сердоликны күп кешеләр 3 нче төркемгә, ягъни кирәк-ярак өчен кулланыла торган ташлар рәтенә кертеп карыйлар. Бу, әлбәттә, хәзерге экономика күзлегеннән чыгып караганда, хаклыкка да туры килә. Әмма алай карау, ташның тышкы ягын гына бәяләү булыр иде. Гарәп илләрендә сердолик әле дә бик югары бәяләнә.

Ташларның кеше сәламәтлегенә йогынты ясый алганы элек-электән билгеле булган факт. Күп кенә галимнәребезнең фикеренчә, сердолик ташы кешедәге төшенкелекне читләштерергә, йөрәк тибешен җайга салырга, кыюлык өстәргә мөмкин. Ислам галимнәре Пәйгамбәребезнең чәнчә бармагында сердолик ташы белән йөзек булган, дип әйтәләр. Аннан үрнәк алып, мондый йөзекләр кию бөтен мөселман дөньясына тарала башлый. Ә соңрак сердоликтан ясалган мөһерле йөзекләр Төркия һәм Иран аша Ауропага да үтеп керә.

Сердолик ташын элек-электән Йәмәндә, Һиндстан һәм Гарәпстанда тапканнар. Бүген инде аны Җир шарының бик күп континентларында табалар дисәң дә була, ә беренче урында Бразилия тора. Безнең якларда сердоликны кайчандыр Кырымда да табалар иде, әмма бүгенге көндә анда бу таш запаслары инде бик аз калган. Анда аны бары тик текә тауларда зур булмаган катламнар рәвешендә генә күреп була. Сердолик вулканнар күп булган җирдә табыла, чөнки аның килеп чыгышы да турыдан-туры вулкандагы лавага бәйле дисәң дә була.

## Зөбәрҗәт ташы



Мөселманнар өчен тагын бер яраткан һәм кыйммәтле саналган таш – зөбәрҗәт. Галимнәребез аны йөрәк тибеше еш булганда, бөер һәм ашказаны авыртканда һәм хәтта эпилепсия өянәкләре булганда да (ул өянәкләрне булдырмый дигән фараз булган) тагып йөрергә кушканнар. Шулай ук Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән зөбәрҗәт күңелгә рәхәтлек бирә, курку һәм шомнарны баса, ялкаулыктан булыша, ә кайбер галимнәр йөкле хатын-кызларга җен керүгә каршы тора, дип тә әйтәләр. Шулай ук зөбәрҗәткә еш карап тору күзләргә файдалы. Зөбәрҗәтнең тагын бер үзенчәлеге бар дип сөйлиләр: әгәр ул ташны агуланган ризык янәшәсенә куйсаң, бу таш тирли башлый икән.

Әлбәттә, зөбәрҗәтнең бизәнү әйберләре өчен дә менә дигән таш икәнен онытырга ярамый. Чәч кыстыргычлары, алкалар һәм йөзекләрнең бүген кибетләрдә нинди генә төре юк.

Зөбәрҗәт табыла торган иң борынгы урын булып Мисыр җирлеге тора. XVI гасырдан алып, XIX гасырга кадәр дөньяга иң сыйфатлы һәм иң күп күләмдә зөбәрҗәт ташын Колумбия тарата. XIX гасыр урталарында Уралда, АКШның кайбер штатларында, Австриядә дә табыла башлый. Соңрак Һиндстанда, Африкада һәм башка җирлекләрдә дә зөбәрҗәтне таба башлыйлар.

## Кызыл якут

Тагын бер уникаль ташларның берсе – якут яки кызыл якут. Ул да шулай ук дәвалануда бик еш файдаланылган. Гомер-гомергә иң яхшы якутлар дип Һиндстан якутлары саналган. Бүгенге көндә бөтендөнья базарына Шри-Ланка, Таиланд кебек Азия илләреннән чыга. Аллаһы Тәгалә ризалыгы белән, бу ташның да еш йөрәк тибеше булганда, кан куерганда, эпилепсия вакытында да ярдәме тияр. Риваятьләр буенча, ул кешедә үз-үзенә ышанычны арттыра, аны төрле коткылардан коткарып кала, диелә.

## Асылташ

Матурлыгы белән сокландыра торган ташларның тагын берсе – хризолит. Ул алтынъяшел төстә була һәм ярымкыйммәтле ташлар төркеменә карый. Аны шулай ук элек-электән төрле коткыларга бирелмәс өчен такканнар. Асылташны беренчеләрдән булып Мисырда тапканнар. Аны кызыл диңгездә урнашкан кечкенә утрауларда күп очратырга мөмкин булган. Бүгенге көндә асылташ Бразилиядә, Италиядә, АКШта, Мексикада, Африкада һәм хәтта Антарктидада да табыла. Күргәнебезчә, асылташ Җир шарының бик күп континентларында таралган, әмма, аңа карап, зур үлчәмле асылташны табу бик сирәк күренеш булып санала.

***

Шулай итеп, без кыйммәтле ташларның ни өчен шулай дип аталганын да, аларның табылу урыннарын да, сәламәтлеккә нинди файдалары булганын да карап киттек. Әмма ташлар үзләре генә берниндн көчкә ия түгеллеген дә исебездән чыгармасак иде. Бу дөньяда бар нәрсә дә Аллаһы Тәгалә кулында. Без исә сәбәп кылып, Аңа тәвәккәл итеп яшәргә тиешбез.

■ **Сәхифәне Габделхәким Фәсхиев әзерләде**



КЫЗЫЛ ЯКУТ

# Мөэминнәрнең анасы – Өмме Сәләмә

### Нәселе

Аның әтисе – Әбү Өмәйә бине Әл-Могыйра – Мәхзүм кабиләсенең иң мәшһүр һәм күренекле җитәкчеләрнең берсе булган. Ул гарәпләр арасында үзенең юмартлыгы белән дан тоткан. Моның өчен аны «мосафирларга изгелек кылучы» дип йөрткәннәр.

Өмме Сәләмәнең ире – Габдуллаһ бине Габделәсәд исемле кеше – беренче ун мөселманның берсе булган. Аңа кадәр Әбү Бәкер белән берничә кеше генә Ислам кабул иткән.

Өмме Сәләмә 580 нче елда Мәккәдә туган. Аның үз исеме Һинд булган, ләкин бөтен кеше дә аны Өмме Сәләмә дип белгәннәр. Бу кушамат киләчәктә аның чын исемен алыштырган.

### Һиҗрәте

Өмме Сәләмә ире белән Ислам кабул итеп, беренче мөслимәләрдән саналган. Эзәрлекләүләр һәм рәнҗетүләр түзә алмаслык дәрәҗәгә җиткәч, Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам мөселманнарга ватаннарын калдырып, Хәбәшкә (Эфиопия) күчеп китәргә рөхсәт иткән. Өмме Сәләмә һәм аның ире мөһаҗирләрнең беренче төркемендә була. Монда күченеп килгәч тә, мөселманнар үз туган якларын бик нык сагыналар һәм озакламый кире әйләнеп кайталар. Ләкин монда мөшрикләр мөселманнарны җәзалап, куркытып, шуннан тәм табалар.

Шушы шартларда Мөхәммәд галәйһиссәлам сәхабәләренә Мәдинәгә күчеп китәргә рөхсәт биргән. Өмме Сәләмә һәм аның ире динне һәм үзләрен саклап, корәешлеләрдән качып китүче беренче мөһаҗирләр була.

Әмма аларның һиҗрәтләре алар уйлаганча гади һәм җиңел эш булып чыкмый. Мәккәдән чыкканда ук аларны Бәнү Мәхзүм, ягъни үз кабиләкешеләре камап алалар: иренә ташланалар, ә үзен кулга төшерәләр. Иренең кабиләсе, ягъни Бәнү Габделәсәд кешеләре улын алып китәләр.

Бу хәлләр барысы да аның күз алдында була. Ул һәр көнне сахрага чыгып, бу фаҗигага булган урында утырган. Шулай бер ел вакыт узып та киткән. Бервакытны агасының улы аны кызганып, кабилә башлыкларыннан аңа карата мәрхәмәтле булуларын сорый. Шул рәвешле, аңа ире янына китәргә рөхсәт итәләр, баласын да үзенә кире кайтаралар. Озак вакыт аерылып торганнан соң гаилә янәдән кушылган.

Шуннан соң ире Бәдер сугышында катнашкан. Аннан Өхед сугышында катнашып, бик каты яраланган. Ярасы ялкынсынып, ул урын өстенә ятарга мәҗбүр булган.

### Иренең вафаты

Авырып ятканда ире хатынына: «Әй, Өмме Сәләмә, мин Аллаһы Илчесенең болай дигәнен ишеттем: «Кемгә дә булса кайгы килсә, ул: «Дөреслектә, без Аллаһыныкы һәм Аңа әйләнеп кайтачакбыз. Әй Аллаһы, мин карышусыз әлеге бәхетсезлекне кабул иттем. Әй Аллаһы, миңа арттырып савап бир», – дип әйтсен, Аллаһы һичшиксез аның теләген үтәячәк».

Түшәктә ятканда аның янына хәлен белергә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам дә килгән. Ул китәргә дә өлгермәгән, Әбү Сәләмә вафат булган. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам үзенең мөбарәк куллары белән аның күзләрен йомдырган.

Мөселманнар барысы да Өмме Сәләмәнең кайгысын уртаклашканнар. Үсеп, тернәкләнергә дә өлгермәгән кечкенә балаларыннан кала, Мәдинәдә аның беркеме дә булмаган.

### Өмме Сәләмәнең Мөхәммәд галәйһиссәлам белән никахы

Өмме Сәләмәнең гыйддәсе беткәч, аңа Әбү Бәкер яучы җибәргән, ләкин ул аның тәкъдимен кабул итмәгән. Аннан соң Гомәр бине Хаттаб тәкъдим ясаган, Өмме Сәләмә аннан да баш тарткан.

Аннан соң Өмме Сәләмә янына Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм килгән. Өмме Сәләмә: «Әй Аллаһының Илчесе, минем өч сыйфатым бар: мин бик көнче хатын, шуңа күрә, син миңа ачуланырсың да, моның өчен Аллаһы мине җәзалар дип куркам. Моннан тыш, мин инде олы яшьтә һәм минем балаларым бар. Минем яктан бернинди ышанычлы кеше дә юк», – дип әйткән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аңа болай дип җавап биргән: «Син үзеңнең артык көнче булуың турында искә алдың. Мин Аллаһыга дога кылып, синең әлеге сыйфаттан котылуыңны сораячакмын. Син үзеңнең яшең турында искә алдың, әмма мин дә синең кебек үк яшьтә. Балаларыңа килгәндә, мин аларны үземнеке дип саныйм. Син үз ягыңнан ышанычлы кеше юк дип әйтәсең. Ләкин андый ышанычлыларның берәрсе монда булса яки булмаса да, сине миңа кияүгә бирергә каршы булган берсе дә юк».

Алар 4 нче һиҗри елда никахлашалар. Өмме Сәләмә үзенең намуслылыгы һәм тәкъвалыгы белән башкалардан аерылып торган. Хатын-кыз сәхабәләр арасында фикһка бәйле мәсьәләләрне яхшы белгән. Шулай ук хәдисләр тапшыруда да ул үзеннән зур өлеш керткән: Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән 378 хәдис тапшырган.


Өмме Сәләмә акыллы, үткен булган, иң авыр хәлләрдән дә чыгу юлларын таба алган. Ул хәтта Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә дә кайбер мәсьәләләр буенча карар кабул иткәндә үз киңәшләрен биргән. Мәсәлән, Хөдәйбия килешүе төзегәннән соң, Аллаһының Илчесе сәхабәләргә корбаннар чалырга һәм чәчләрен кыркырга (ихрамнан чыгарга) боера. Ләкин сәхабәләр килешүнең шартлары белән ризалашсалар да, Мөхәммәд галәйһиссәламнең әмерен тыңламыйлар. Аллаһының Илчесе үз сүзләрен өч тапкыр кабатласа да, беркем ул әйткәнчә эшләргә ашыкмый. Пәйгамбәребез галәйһиссәламне бу хәл бик борчый һәм ул бу турыда Өмме Сәләмәгә дә әйткән. Өмме Сәләмә исә аңа: «Йә Аллаһының Илчесе, әмереңне үтәүләрен телисеңме? Бар үзең корбан чал һәм чәчеңне кыалдырт. Сәхабәләргә бернәрсә дә әйтмә!» – дип әйткән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аның киңәшен тыңлаган. Сәхабәләр дә аның артыннан нәкъ шулай эшләгәннәр.

Мөэминнәрнең анасы Өмме Сәләмә һиҗри белән 61 нче елда 84 яшендә вафат була. Җеназа намазын аңа Әбү Һөрайра укый. Аны Җәннәт Әл-Бакыйгъ зиратына күмәләр.

■ **Лилия Хәләфетдинова**

# Әл-Бакыйгъ нинди урын ул?



Мәдинәдә булган мөселманнар, башка изге һәм истәлекле урыннар белән беррәттән, Әл-Бакыйгъ каберлеген дә зиярәт итәргә омтыла. Күпләребез аның турында ишеткәндер. Бу урынның тарихы һәм үзенчәлеге белән танышып китик.

Әл-Бакыйгъ – бик йомшак туфраклы, ташсыз җирлек. Ул Мәдинә шәһәрендә, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм мәчете янында урнашкан. Расүлуллаһ Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылганда бу урын әнәле куаклар үсеп утырган ташландык бер җир булган. Мәчет төзегәндә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аны ике ятим баладан сатып ала.

Беренче булып Бакыйгъта Әсәд бине Зәрара радыяллаһу ганһе исемле сәхабә дәфен кылына. 624 елда, Бәдер сугышы барган вакытта, авырудан Пәйгамбәребезнең кызы Рокыя радыяллаһу ганһә үлеп китә. Аны да шушы зиратта җирлиләр. Ә Бәдер сугышы тәмамланганнан соң, монда Госман бине Мәгъзунны күмәләр. Бакыйгъ зиратында барлыгы ун меңгә якын сәхабә җирләнгән.

Зиратка кергәндә үк, Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең кызлары Өмме Көлсем, Рокыя, Зәйнәб күмелгән. Монда ук аның абзыйсы Габбас. Пәйгамбәребезнең яраткан кызы Фатыйма һәм аның улы Хәсән дә монда җирләнгән. Аларның барчасыннан да Аллаһы Тәгалә разый булсын. Шушы каберстанда имам Мәлик, башка әүлияләр, галимнәр дә дәфен кылынган.

1925 елның маенда Бакыйгъта кабер ташларын җир белән тигезлиләр. Шул сәбәпле, бүгенге көндә бар каберләрне дә табып булмый.

Бакыйгъ зираты кайбер хәдисләрдә искә алына. Расүлуллаһ монда еш килгән, мәрхүмнәр өчен догалар кылган. Күпсанлы сәхабәләр, Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең гаилә әһелләре, Ислам галимнәре монда күмелгәнлектән, ул һәр мөселман өчен зур әһәмияткә ия урын. Мөселманнар бу урынны зиярәт итәргә, мөхтәрәм кардәшләре өчен дога кылырга омтыла.

# Ач шәкерткә бүләк



Димәшкъ шәһәрендә бер шәех яшәгән. Ул «Тәүбә» дип аталган мәчеттә дәресләр биргән.

Шәехнең бик фәкыйрь бер шәкерте була. Бу шәкерт, акчасы булмаганлыктан, берничә көн рәттән берни ашамый йөргән. Беркөнне шәкерт шулкадәр ач була, хәзер берәр нәрсә ашамаса, үзенең үләчәген аңлый. Шул вакыт ул: «Бүген минем үләксә яки хәтта берәр нәрсә урлап ашарга хакым бардыр – мин бит ачтан үләм!» – дип уйлый. Шулай егет Димәшкънең тар урамнары буенча ризык эзләп китә... Бу шәһәрдә урамнар бик тар һәм кыек булып, балконнар бер-берсенә якын булганлыктан, берәр түбәгә менү һәм өйгә керү җиңел була.

Шулай шәкерт бер түбәгә менә, шуннан ялгыш кына нindидер хатын-кызларны күреп ала, һәм Аллаһыдан куркып, тиз генә борыла. Шул вакыт аның күзе ишегалдына төшә. Анда казан кайнап торганлыктан, тирә-якка искиткеч тәмле ис тарала. Шәкерт ишегалдына сикереп төшә дә, казан янына йөгереп килеп, капкачын ачып җибәрә. Пешеп торган тутырылган баклажаннарны күреп, егет аларның кайнар булуын да онытып, берсен алып тешли. Шул ук мизгелдә ул үзенә килә: «Ни бу?! Мин, шәригать белеге шәкерте, кеше йортына кереп, ризык урлыйм!» Тешләнгән баклажанын кире казанга ыргытып, шәкерт мәчетенә йөгерә. Аңын югалтып егылмас өчен, ул сөялеп утыра да, остазын тыңлауны дәвам итә.

Сабак тәмамланганнан соң, барысы да тарала. Шәкерт мәчеткә килгән бер хатын-кызны күрә. Ул вакытта Димәшкътә бар хатын-кызлар пәрәнҗәдән йөргәнлектән, бу ханым да пәрәнҗәдән була. Мөслимә шәех янына килеп, аннан әкрен генә нидер сораштыра башлый. Шәех тирә-якка күз сала да, әлеге шәкерттән кала беркемне күрми, аны үз янына чакырып ала. «Син өйләнергә теләмисеңме?» – дип сорый ул. Ач шәкерт көчкә елмаеп: «Ий остазым, мин ачтан үләм, минем бөтенләй ризыгым юк! Ничек өйләним инде?» – ди. Шәех: «Борчылма! Бу хатын тол калган, аның торыр өе бар һәм ул ир эзли. Ул карт апасы белән бергә яши, алар бу шәһәрдә ялгыз, җәберләүче һәм талаучылардан сакланыр өчен, аңа кияүгә чыгарга кирәк. Син ризамы?» – дип җавап кайтара. Егет: «Әйе, шәехем», – ди.

Шәех шәкерте өчен мәһәр биреп, аларга никах укый. Өйләренә кайткач, хатын пәрәнҗәсен сала, һәм шәкерт хәләл җефетенең бик тә чибәр икәнлеген күрә. Хатын: «Син ачмы?» – дип сорый һәм казанын алып керә. Аны ачуга: «Йә Аллаһ! Кемдер баклажанны тешләгән!» – дип кычкырып җибәрә. Шәкерт үксеп елый башлый һәм булган вакыйгаларны сөйләп күрсәтә.

Хатын боларны ишеткәч, Аллаһыга мактаулар укып: «Менә Аллаһыдан куркуыңның җимешләре. Харам ризыктан баш тартканың өчен, Ул сине чибәр хатын һәм зур йорт белән бүләкләде!» – ди.

# Кәгазь кисәгендә Аллаһы исеме



Фөзәйл бине Гыйәд исемле сәхабә яшь чагында күп гөнаһлар кылган, әмма, Аллаһының рәхмәте белән, тәүбә кылып, хакыйкать юлына баскан һәм зур дәрәҗәләргә ирешкән.

Бервакыт ул дәресләрдән соң шәкертләре белән әңгәмә корып утырган. Бер шәкерте: «Остаз, туры юлга басканчы, синең берәр изгелек эшләгәнең булдымы?» – дип сорый.

Фөзәйл бине Гыйәд түбәндәге вакыйганы сөйләп күрсәтә. «Вәллаһи, бер гамәлдән кала, башка яхшылык эшләгәнемне хәтерләмим. Бервакыт мин бик ачыккан һәм сусаган хәлдә чүплек яныннан узып бара идем. Анда Аллаһы исеме язылган кәгазь кисәге ятканын күрдем. Мин аны шунда калдырып узып китәргә курыктым һәм күтәрдем. Ул вакытта минем бер динар гына акчам бар иде. Шул акчага ашарга алырга уйлый идем. Әмма мин якындагы беренче базарга юнәлдем дә, хушбуйлар сатучыны табып, шул бер динарга ислемай сатып алдым. Шуннан бу кәгазь кисәген ислемайга салып, хуш ис сеңдерүен көтеп тордым да, аны югары бер урынга элеп куйдым. Ач һәм сусаган халәттә мин йоклап киттем.

Төштә мин бер тавыш ишеттем. Ул миңа: «Син Минем исемемне олылаган кебек, Мин дә синекен һичшиксез олылармын», – диде».

# «Син миңа суккач, мин Аллаһыдан сиңа җәннәт сорадым»



Бервакыт Ибраһим бине Әдһәм дала буйлап барганда, каршысына бер хәрби очрап: «Иң якын авыл яки шәһәр кайда монда?» – дип сорый. Ибраһим хәзрәт зиратка төртеп күрсәтә. Хәрби ачуланып, аның башына сугып җибәрә, сүгенеп, юлын дәвам итә. Ерак китми, ул юлчыларга тап була. Алар хәрбигә аның бик тәкъва һәм гыйлемле кешене түбәнсеткәнен әйтә. Хәрби, кылган гамәленә үкенеп, Ибраһим бине Әдһәм янына әйләнеп кайта һәм гафу үтенә башлый. Ә хәзрәт аңа: «Син миңа суккач, мин Аллаһы Тәгаләдән сиңа җәннәт сорадым», – ди. Хәрби бик гаҗәпләнә: «Ни өчен?!» – дип сорый. Ибраһим бине Әдһәм: «Бу авыртуны кичергәнем өчен Аллаһы Тәгалә миңа һичшиксез савап бирәчәк. Мин алачак савап өчен сиңа җәза булуын теләмәдем», – дип җавап кайтара...

Ибраһим бине Әдһәм бик бай гаиләдә туа, әмма ата-ана йортын һәм мул тормышын калдырып, гомерен гыйлем алуга багышлый, һәрвакыт юлда була. Ул бик оста телле галимнәрнең берсе була. Уңыш җыеп, кешеләрнең бакча һәм хуҗалыкларын саклап көн күрергә акча эшләгән.

# Коръән-хафиздан 20 киңәш

**Бөтен дөньяга танылган Коръән-хафиз, Коръән укучы (кари) һәм нәшидләр башкаручы Мишари Рәшид 1976 елда Күвәйттә туа. Тулы исеме – Әбү Рәшид Мишари бине Рәшид Әл-Гафәси. Күвәйттәге Мәсҗидүл-Кәбирнең имам-хатыйбы булып тора. Хафиз Аллаһының Изге Китабын ятларга теләүчеләргә үзенең 20 киңәшен бирә.**



**1. Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен ятлау.**

Кызганыч, еш кына без изге гамәлләр эшләгәндә бер хатаны кабатлыйбыз: безнең ниятебез Аллаһы ризалыгы өчен түгел, ә кемдер алдында мактану, башкалардан артта калмау теләге булырга мөмкин. Юкка гына хафиз бу киңәшне беренче итеп куймаган. Белгәнебезчә, күпчелек имамнар, шулар арасында имам Бохари белән Мөслим дә, үзләренең хәдис җыентыкларын ният турындагы хәдис белән башлаган.

Алга таба хафиз: «Бу ниятне Коръәнне өйрәнү һәм ятлауның файдасы турында, аны өйрәнүчеләр һәм хафизләрнең дәрәҗәсе хакында белеп дөресләргә мөмкин. Сахих хәдистә: «Арагыздан иң яхшысы – ул Коръәнне өйрәнүче һәм аны башкаларга өйрәтүче», – дип әйтелә», – ди.

**2. Максатны билгеләү (үзеңә максат кую).**

Мисал өчен: «Кардәшләрем белән тәҗвид өйрәнәчәкмен һәм Коръәннән бер җүз ятлаячакмын».

**3. Вакыт һәм мөмкинлекләрне дәресләрне калдырмаслык һәм ятлауда артта калмаслык итеп планлаштыру.**

Ягъни теләк булуы гына җитми, максатка ирешү өчен сәбәбен күрергә дә кирәк. Мисал өчен: «Дүшәмбе көнне эшләрем күп, әмма сишәмбе берничә буш сәгатем бар, шул вакыт эчендә өйрәнгәннәрне кабатларга, Коръәннән яңа аятьләр ятларга мөмкин».

Көн тәртибегез булса һәм сез моңа игътибар бирсәгез, ин шә Аллаh, моның нәтиҗәсе дә булачак.

**4. Үзегезгә иң уңайлы вакыт һәм урынны билгеләү.**

**5. Ятлау өчен үзеңә билгеле бер Коръән китабын сайлау.**

Ягъни, без ишетеп тә, күреп тә хәтердә калдырабыз. Ятлау җиңелрәк барсын өчен, бер китапны сайлап алу дөрес булачак: күзләрегез аның шрифтына өйрәнәчәк, сез китапларда төрлечә билгеләнергә мөмкин булган тамгаларга инде игътибар итмәячәксез.

**6. Башта туачак кыенлыклардан курыкмагыз.**

Гадәттә, беренче мәлдә күпләрдә дөрес әйтелеш, хәтергә бәйле кыенлыклар була. Ә ятлау спортка охшаган – беренче көнне сөяләр барлыкка килсә дә, бу спортны ташларга кирәк дигән сүз түгел. Дәреслектә, бу бик күп мөселманнарның проблемасы. Ниндидер изге эшне калдырту өчен, шайтан бик күп төрле сәбәпләр табачак.

**7. Коръәнне үзлектән ятласагыз, ятлаган өлешләрне дөрес укый белүче шәехкә (остазга) тикшертегез.**

«Бу киңәшнең әһәмиятлелегенә мине бер шәех тикшергәннән соң инандым. Мин зур булмаган бер сүрәне инде берничә ел һәм бик яхшы беләм, дип уйлый идем. Әмма төзәтергә кирәк булган берничә хатам барлыгы ачыкланды. Шуңа күрә, бер генә сүрәне дә тикшертми калмагыз», – дигән хафиз. Моны шулай ук диск яки аудиотасма буенча тикшереп була, иң мөһиме – барысы да яхшы ишетелсен. Шулай ук Мишари Рәшид укуның матурлыгы белән мавыкмаска, ә беренче чиратта дөрес әйтелешкә игътибар бирергә киңәш итә.

**8. Коръәнне өйрәнгәндә яки ятлаганда кыскача тәфсиргә мөрәҗәгать итәргә.**

Һәрвакыт җитди тәфсирне уку игътибарны башкага юнәлтергә мөмкин, ятлаучы болай үз максатына ирешмәячәк.

**9. Беркемгә дә комачауламаганда, кычкырып укырга.**

Болай хәтердә күбрәк калачак. Сүрәләрне ятлаганда, башта бер аятьне, аннан икенчесен ятлагыз, шуннан соң аларны бергә укыгыз һәм шул рәвешле өстәп, арттырып барыгыз.

**10. Ятлаганны туганнарыгыз, кардәшләрегез алдында укыгыз.**

Шул рәвешле сез кимчелекләрегезне ачыклаячаксыз, үзегезгә ышанычыгыз артачак, шулай ук үзегез һәм дусларыгызның вакытын Коръән белән бизиячәксез.

**11. Ятланганны кабатлап тору.**

Бигрәк тә моны намазда эшләү файдалы – бу иң яхшы тикшерү булыр. «Шулай ук һәрвакыт бер үк сүрәләрне генә кабатларга кирәкми. Мисал өчен, башта мин 10 сүрәне ятлап белә идем, әмма намазда еш кына аларның яртысын укыдым. Нәтиҗәдә, намазда укыган сүрәләрне мин намазда кулланмаганнарыннан яхшырак белә идем. Моны булдырмаска тырышыгыз». Төрле сүрәләрдәге охшаш аятьләргә аеруча игътибар итегез.

**12. Гыйлемнәрегез гомерлек булсын өчен, ятлаганнан соң гөнаһ кылмаска тырышыгыз.**

Гөнаһларыбыз аркасында Аллаһы Тәгалә безнең гыйлемнәребезне алырга мөмкин, Ул бозык кешеләргә дини белем бирми.

**13. Коръән укыла торган түгәрәкләргә йөрегез.**

Ягъни Коръәнне ятлый торган урыныгыздан тыш, Изге Китап укыла торган башка урыннар табыгыз. Монда укучылар арасында яхшы укый белүче, кирәк булганда төзәтүче булуы мөһим. Мисал өчен, кайбер мәчетләрдә намаздан соң яки махсус көннәрдә җыелып, чиратлашып Коръән уку гадәте бар. Мәчет имамы хаталарны төзәтеп, җәмәгатькә нәсыйхәт ясап җибәрергә мөмкин.

**14. Коръәнне өйрәтергә рөхсәте (иҗазәсе) булган кешегә мөрәҗәгать итегез.**

Үзлектән ятлаучының зур хаталары булырга мөмкин, шуңа күрә билгеле бер өлешне (җүз, ярты җүз, ярты Коръән) ятлаганнан соң, үзегезгә иҗазәле остаз табыгыз.

**15. Хәтерегез яхшы булган вакыт, яшьлегегездән файдаланыгыз!**

Әгәр сез олы яшьтә ятлый башласагыз, күбрәк тырышлык куярга кирәк булачак.

**16. Гыйлем алучы һәм Коръән ятлаучы туклану рәвешен тикшерсен.**

Монда Мишари Рәшид «Симезлек зирәклекне киметә» дигән мәкаль китерә. Коръәнне ятлаучы артык күп ашарга тиеш түгел, моннан йокы килә башлаячак.

**17. Ятлауны планлаштыру белән артык мавыкмагыз.**

Кайберәүләр план төзүгә ятлауның үзеннән күбрәк вакыт сарыф итә. Шулай ук бер ятлау рәвешеннән башкаларына күчмәгез.

**18. Беренче уңышларыгыздан соң ук, үзегездән канәгать булмагыз, мин-минлектән сакланыгыз.**

**19. Ялкаулыктан дога кылыгыз.**

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам көчсезлек һәм ялкаулыктан мондый дога кылырга киңәш иткән: «Аллаһуммә, инни әгуузү бикә минәл-гаҗзи вәл-кәсәл». Мәгънәсе: «Алла-һым, көчсезлек һәм ялкаулыктан Сиңа сыенам!»

**20. Аллаһы Тәгалә сезгә бу гыйлемнәрне бирсен дип, дога кылыгыз.**

Монда үз туган телеңдә дә, гарәпчә дә төрле догалар кылырга була. Мисал өчен, Коръәндә килгән бу доганы: «Рабби, зидни гыйлмән» – «Раббым, гыйлемемне арттырчы!» – укырга була.

Шулай итеп, бу кадерле дин кардәшебез, Коръән-хафиз Мишари Рәшиднең 20 киңәше иде. Алар Коръәнне укырга өйрәнүчеләргә дә, ятлаучыларга да бик файдалы булыр.

# Каһвә тарихыннан



Бүген каһвә иң киң таралган эчемлекләрнең берсе булып тора. Интернет челтәрендә китерелгән мәгълүматларга караганда, дөньяда нефтьтән соң иң зур күләмнәрдә сатыла-алына торган товар – каһвә. Җир шарында ел саен ике миллиард долларлык каһвә сатыла.

Бүгенге көндә бу эчемлек Ауропада бик популяр булса да, белгәнебезчә, чәй, каһвә һәм тәмләткечләр шәрык дөньясыннан тарала башлаган. Каһвәне әүвәл нәкъ мөселман илләрендә эчә һәм үстерә башлаганнар.

Риваять буенча, каһвә агачының үзенчәлекле сыйфатларына беренче булып Хәбәшстанда (Эфиопия) бер көтүче игътибар итә. Бервакыт көтүче кәҗәләрен каһвә агачлары үскән тау итәгендә көткән. Шушы агачларның яфракларын ашаган кәҗәләр котырынып йөгерешә һәм сикергәли башлаганнар. Кешеләр бу агачның җимешләреннән кайнатма ясап эчеп караганнар, шул рәвешле аның көч биреп, дәртләндереп җибәрә торган сыйфатын ачканнар. Каһвә тирәяктагы авылларга да бик тиз тарала.

Башка бер риваять буенча, каһвәнең сыйфатларын Габделкадир Әл-Җәзири исемле Йәмән галиме ачкан. Бу галим дару үләннәрен һәм гомумән үләннәрнең төрле сыйфатларын өйрәнгән. Каһвә агачының да яфрак һәм орлыкларын тикшереп караган, һәм бу үсемлектән ясалган эчемлекнең тәме аңа бик ошаган. 1587 елда Габделкадир каһвәгә багышланган беренче хезмәтне язган.

«Каһвә» – гарәп сүзе, ул «каһкаһә» – «кычкырып көләргә» сүзеннән ясалган, дигән фараз бар. Эчемлек кәефне күтәргәнгә, көч өстәгәнгә күрә, аның атамасын да көлүгә бәйләгәннәр булса кирәк. Соңрак «каһвә» сүзе (нигездә төрек теле аша) башка бик күп телләргә кереп китә.

Башта каһвәне дару буларак, баш авыртуыннан һәм ашказаны эшләмәүдән кулланганнар. Англия табиблары каһвәне эчәкләр авырулары һәм истерия кебек нерв авыруларыннан киңәш иткәннәр. Алар каһвәнең аң-зиһенне арттыру, күңелне тынычландыру һәм кәефне күтәрү кебек сыйфатларга ия булуына ышанганнар.

Йәмәндә каһвәне суфилар кулланган. Каһвә аларга төннәрен йокламыйча зикердә үткәрергә ярдәм иткән. Бу мәгълүмат XV гасыр истәлекләрендә сакланып калган.

Дөньядагы беренче каһвә бакчасы (плантация) да хәзерге Йәмән территориясендә урнашкан була. Аннан эчемлек Каһирә, Димәшкъ, Багдад, Истанбул шәһәрләренә җибәрелә. 1645 елда Венеция шәһәрендә беренче каһвәханә ачыла. 1652 елда – Англиядә. Ауропада каһвәханәләрне «пенни университетлары» дип атый башлыйлар, чөнки бу йортларда каһвә өчен генә вак акча түләп, заманасының иң гыйлемле кешеләрен очратырга һәм әңгәмә корырга мөмкинлек туган. Каһвәханәләргә зыялылар, журналистлар җыелып, дөньядагы хәлләр, яңалыклар хакында фикер алышкан, сәүдәгәрләр, эшмәкәрләр үз килүшеләрен төзегән, ир-атлар сәясәт турында сөйләшергә җыелган.

Әмма каһвә белән көрәшүчеләр дә табылган. Ауропа руханилары башта бу эчемлеккә каршы чыккан, аны Ислам йогынтысы дип кабул иткән һәм хәтта «төрекләрнең кара каны» дип атаган. Англия короле Карл II каһвәханәләрне ябарга боерык биргән, ләкин халык моның белән килешмәгәч, аннан баш тарткан.

Безнең илдә каһвә Петр I вакытында тарала. Беренче «каһвә йорты» 1740 елда ачыла. Бүгенге көндә Россия каһвә иң күп эчелә торган ун илнең берсенә керә.

Каһвәнең сәламәтлек өчен файдалы яки зарарлы булуы хакындагы бәхәсләр бүген дә туктатылмый. Күпсанлы тикшеренүләр кайвакыт бер-берсенә капма-каршы килә торган нәтиҗәләр бирә.

Әлбәттә, каһвәнең көч өстәве, кәефне күтәреп җибәрүе бәхәссез. Тик сәламәтлек өчен бу файдалымы соң? Әлеге тәэсир берничә сәгатьтән соң үтә, ә аннан соң кеше арыганлык сизә башлый, даими рәвештә каһвә эчүчеләр ансыз үзләрен кәефсез хис итә. Каһвә кан басымын күтәрә. Кайбер тикшеренүчеләр каһвә төрле яман шешләрдән сакларга мөмкин, дигән фикерләр дә әйтә, әмма әлегә моның ачык дәлилләре юк.

# Аллаһы нинди җимеш белән ант итә?



Коръәннең 95 нче «Әт-Тин» («Инҗир») сүрәсе: **«Инҗир җимеше вә зәйтүн агачы белән ант итәм»**, – дигән аять белән башлана. Тәфсирчеләр фикеренчә, бу ике агач бик файдалы булганга һәм Шам җирләрендә киң таралганга күрә, Аллаһы Тәгалә нәкъ алар белән ант иткән. Шулай ук тәфсирләрдә инҗир ашарга яраксыз төшләре булмаган, чиста җимеш буларак искә алына.

Инҗир кешеләргә билгеле булган иң борынгы җимешләрнең берсе. Борынгы Элладада ул безнең эрага кадәр IX гасырда ук билгеле булган. Борынгы Мисырда ул хәтта изге агач булып саналган.

Инҗир агачының биеклеге 8 метрга җитә, ул елына ике тапкыр уңыш бирә. Агач 2–3 елдан соң җимеш бирә башлый, гадәттә 30–60, ә кайвакыт 300 ел яши.

### Инҗирнең файдасы

Инҗир җимешләре аксым, шикәр, тимер, B1, B3, PP, C витаминнары, натрий, калий, кальций, магний, фосфор кебек матдәләргә бай.

Җимешнең файдалы сыйфатлары аны халык медицинасында киң кулланырга мөмкинлек бирә. Инҗир төнәтмәсен салкын тигәндә, тын алу әгъзалары, теш уртлары ялкынсынганда, талак (селезенка) һәм бавыр авыруларыннан кулланалар. Калийга бай булганга, инҗир йөрәк авыруларыннан интегүчеләргә аеруча файдалы. Ашказаны-эчәк трактының эшчәнлеген яхшырту өчен көн дә ике инҗир җимеше ашарга киңәш ителә.

Әмма ашказаны яки эчәк ялкынсынуы, шикәр авыруы белән авыручыларга инҗирне кулланырга киңәш ителми.

Инҗир җимешләрен яшь килеш тә, киптереп тә ашыйлар, алардан кайнатма ясыйлар. Инҗирне боткаларга, эремчеккә, катык, йогыртка өстәп ашарга була. Аларны ипи, пудинг пешергәндә кулланалар, ит ризыклары белән томалап пешерелгән инҗир бирәләр.

Шул рәвешле, Раббыбыз Изге Китабында искә алган, аның белән ант иткән инҗир – тәмле җимеш кенә түгел, ә күпсанлы витамин һәм файдалы матдәләр хәзинәсе дә.

«Әт-Тин» – «Инҗир» сүрәсендә Аллаһы Тәгалә кешене иң күркәм сурәттә яратуын һәм иман китереп, изге гамәлләр кылучы мөэминнәргә хисапсыз әҗер-савап бирәчәген хәбәр итә. Сүрә «Әллә Аллаһы Тәгалә иң гадел Хөкемдар түгелме?» сүзләре белән тәмамлана. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бу аятьне укыганнан соң: «Әйе, бу шулай. Мин моңа шәһадәт китерүчеләрнең берсе», – дип әйтү хәерле булыр, дигән. Һәммәбезгә бу хакыйкатькә инанучылардан һәм Раббыбыз биргән нигъмәтләрне дөрес файдаланучылардан булырга насыйп булсын иде!

*Сәхифәне Рәмзилә Шафикова әзерләде*

## «Шиһабетдин Мәрҗанинең хаҗ сәфәре»




Хаҗ сәфәре – фарыз гамәл һәм һәр мөселман тормышында олы вакыйга. Йөз ел элек татар кешесе хаҗга нинди юл белән барган? Изге урыннарны күрер өчен күпме вакыт таләп ителгән? Бу хакта бөек татар галиме, дин әһеле, фәлсәфәче Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтнең хаҗнамәсендә бәян ителә. Мәгърифәтче 1880 елда хаҗ сәфәренә чыгып, галимнәр белән очрашулардан, төрле шәһәрләрдән тәэсирләрен хәтер дәфтәрендә теркәп барган. Шушы хатирәләрне аерып алып, аңлатмалар биреп, Ризаэтдин Фәхретдин басмага әзерли.

«Хозур» нәшрият йорты әлеге хезмәтне хәзерге татар әдәби теленә күчереп, 1898 елда гарәп имләсендә чыкан нөсхәне дә кертеп, «Шиһабетдин Мәрҗанинең хаҗ сәфәре» китабын нәшер итте.

**Китапны http://huzurshop.ru сайтыннан яки Казан шәһәре, Газовая урамы, 19 нчы йорт (РИИ бинасы) һәм Тукай урамы, 36 нчы йорт адреслары буенча урнашкан кибетләрдән алырга мөмкин.**
**Телефон: +7 (903) 305-45-43**




**«Дин вә мәгыйшәт» газетасына 2019 елның икенче яртысына язылу башланды**

- Ярты елга язылу бәясе: 132 сум
- Газета айга бер тапкыр чыга
- Язылу индексы: П4333

Түбәндәге сайтларда да язылу мөмкин:
podpiska.pochta.ru һәм uslugi.tatarstan.ru сайтының «Подписка» бүлегендә.

دين و معيشت
дин вә мәгыйшәт

Белешмәләр өчен телефон: 598 09 42

### КАЗАН ӨЧЕН ФЕВРАЛЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз: Сәхәр тәмам | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.02.2019 | 05:29 | 06:08 | 07:38 | 12:00 | 14:25 | 16:16 | 18:03 |
| 02.02.2019 | 05:27 | 06:06 | 07:36 | 12:00 | 14:27 | 16:18 | 18:05 |
| 03.02.2019 | 05:26 | 06:04 | 07:34 | 12:00 | 14:29 | 16:20 | 18:07 |
| 04.02.2019 | 05:24 | 06:02 | 07:32 | 12:00 | 14:31 | 16:23 | 18:09 |
| 05.02.2019 | 05:23 | 06:00 | 07:30 | 12:00 | 14:33 | 16:25 | 18:11 |
| 06.02.2019 | 05:21 | 05:58 | 07:28 | 12:00 | 14:35 | 16:27 | 18:13 |
| 07.02.2019 | 05:19 | 05:56 | 07:26 | 12:00 | 14:37 | 16:29 | 18:14 |
| 08.02.2019 | 05:18 | 05:54 | 07:24 | 12:00 | 14:39 | 16:31 | 18:16 |
| 09.02.2019 | 05:16 | 05:52 | 07:22 | 12:00 | 14:41 | 16:34 | 18:18 |
| 10.02.2019 | 05:14 | 05:50 | 07:20 | 12:00 | 14:43 | 16:36 | 18:20 |
| 11.02.2019 | 05:12 | 05:47 | 07:17 | 12:00 | 14:45 | 16:38 | 18:22 |
| 12.02.2019 | 05:10 | 05:45 | 07:15 | 12:00 | 14:47 | 16:40 | 18:24 |
| 13.02.2019 | 05:08 | 05:43 | 07:13 | 12:00 | 14:49 | 16:42 | 18:26 |
| 14.02.2019 | 05:06 | 05:41 | 07:11 | 12:00 | 14:51 | 16:44 | 18:28 |
| 15.02.2019 | 05:04 | 05:39 | 07:09 | 12:00 | 14:53 | 16:47 | 18:30 |
| 16.02.2019 | 05:02 | 05:36 | 07:06 | 12:00 | 14:54 | 16:49 | 18:32 |
| 17.02.2019 | 05:00 | 05:34 | 07:04 | 12:00 | 14:56 | 16:51 | 18:34 |
| 18.02.2019 | 04:58 | 05:32 | 07:02 | 12:00 | 14:58 | 16:53 | 18:36 |
| 19.02.2019 | 04:56 | 05:29 | 06:59 | 12:00 | 15:00 | 16:55 | 18:38 |
| 20.02.2019 | 04:54 | 05:27 | 06:57 | 12:00 | 15:02 | 16:57 | 18:40 |
| 21.02.2019 | 04:51 | 05:25 | 06:55 | 12:00 | 15:04 | 17:00 | 18:42 |
| 22.02.2019 | 04:49 | 05:22 | 06:52 | 12:00 | 15:06 | 17:02 | 18:44 |
| 23.02.2019 | 04:47 | 05:20 | 06:50 | 12:00 | 15:08 | 17:04 | 18:46 |
| 24.02.2019 | 04:45 | 05:17 | 06:47 | 12:00 | 15:10 | 17:06 | 18:48 |
| 25.02.2019 | 04:42 | 05:15 | 06:45 | 12:00 | 15:12 | 17:08 | 18:50 |
| 26.02.2019 | 04:40 | 05:13 | 06:43 | 12:00 | 15:14 | 17:10 | 18:52 |
| 27.02.2019 | 04:37 | 05:10 | 06:40 | 12:00 | 15:16 | 17:12 | 18:54 |
| 28.02.2019 | 04:35 | 05:08 | 06:38 | 12:00 | 15:17 | 17:15 | 18:56 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Гыйнвар саны, №1 (282)*

Баш мөхәррир: **Сәмигуллин К. И.**
Мөхәррир: **Шафикова Р. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:** 420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБӘРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2745
Газетага ярты елга язылу бәясе – 132 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 22 нче гыйнварда таратыла.
График буенча бу санга 21 нче гыйнвар көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.